**Казан (Идел буе) федераль университеты**

**Алабуга институты**

**Татар филологиясе кафедрасы**

**Ә.С.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Г.Ф.ДАУТОВ**

# 1917-1960 ЕЛЛАР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

**уку әсбабы**

Казанский (Приволжский)
Федеральный университет

**КАЗАН**

**2021**

**УДК 811.512.145(075). 8**

**ББК 83.3.(2 Р–6Т) я73**

**Т 23**

Казан федераль университетының Алабуга институты гыйльми советы карары белән басыла (беркетмә № 9, 28.10.2021)

**Рецензентлар**: филология фәннәре кандидаты, КФУның Алабуга институты доценты ***Габидуллина Ф.И.*** филология фәннәре кандидаты Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты ***Галиуллин Р.Р***

**Хәйруллина Ә.С., Даутов Г.Ф. 1917-1960 еллар татар әдәбияты**: уку әсбабы / Ә.С. Хәйруллина, Г.Ф. Даутов – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2021.-112 б.

**Аннотация:** Тәкъдим ителә торган уку әсбабында 1917-1960 еллар татар әдәбиятына кыскача күзәтү үткәрелә. Әдәбият үсешенең төп этаплары, теге яки бу үзгәрешләр барлыкка килүгә йогынты ясаган төп факторлар игътибар үзәгенә алына. Әйдәп баручы язучылар иҗатына кыскача анализ ясала, әдәби процесстагы урыннары билгеләнелә.

© Казан федераль университеты (Алабуга институты)

© Хәйруллина Ә.С.

Даутов Г.Ф.

# КЕРЕШ
# 1917-1960 ЕЛЛАР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

**Аннотация:** Большевиклар идеологиясенең әдәбият үсешенә тискәре йогынтысы. Вульгар социологизм чәчәк ату. Әдәби иҗат процессын чынбарлыкны пассив фиксацияләүгә кайтарып калдыру.

Гражданнар сугышы һәм әдәбият. Вульгар социологизм. Илне индустрияләштерү, дингә каршы көрәш, яшьләрнең яңа тормыш өчен көрәш алып баруларын сурәтләүнең катгый таләп итеп куелуы.

**Мөһим сүзләр:** Революция, сыйнфыйлык, пролетар әдәбият, футуризм, имажинизм.

1917 елга кадәрге татар әдәбиятының тарихы дистә гасырлар белән исәпләнә. Әдәбият сәнгатьнең иң үтемле төре буларак кешеләрнең акыл хисләренә генә йогынты ясамыйча, аларда иҗтимагый аң да тәрбияләп килгән. Элек-электән дә идарәчеләр үз тәхетләрен ныгыту өчен шагыйрьләр, язучылар, сәнгать әһелләре файдаланган булсалар да, 1917 елдан соң әдәбият тулаем дәүләт идарәчеләренең карамагына күчә, өстән кушканны язу гомум төс ала. 20-30 елла татар әдәбияты тарихы өчен каршылыклы, катлаулы, буталчык дәвер булып тора. 1917 елда хакимияткә большевиклар килгәч, әдәбият аларның максатларына гына буйсындырыла башлый. Матур әдәбият ике сыйныф **буржуазия һәм пролетариат** үлчәвенә салынып карала башлый. Әдәбиятта сыйнфыйлык абсолютлаштырыла. Күп гасырлык классик әдәбиятыбыз (аеруча XX йөз башы татар әдәбияты) 20-30 еллар әдәбиятында кискен каршы куелып марксистик-ленинчыл идеология күзлегеннән бәяләнә башлый. Классик әдәбиятның миллилеге, халыкчанлыгы, дини-әхлакый характерда булуына каршы аяусыз көрәш башлана.

Миллилек интернационализмга каршы куела, үз милләтеңне, интернациональлеккә каршылык дип саналуы, милләтчелек, дип тамгаланды. 20-30 елларда халыклашкан социологизм таләпләре әдәбиятта XX гасырның 90

елларына кадәр дәвам итте. Каләм әһелләренең нәрсә турында язуы, нинди сәнгать чаралары кулллануы һәрвакыт өстән күзәтелеп торды.

Бүген татар әдәбияты алдына, узган гасырның 20-30 елларда большевиклар хакимлегендә калган әдәби хәрәкәтне яңача карау бурычы куелды. Әдәбият галимнәре: Фоат Галимуллин, Рим Салихов, Азат Әхмәдуллин, Альберт Яхин, Мансур Хәсәнов, Флүн Мусин, Масгуд Гайнутдинов, Назим Ханзафаров, Таһир Гыйләҗев, Ильмира Галиева һ.б. бу чор әдәбиятын өйрәнгәндә тарихи хакыйкатьне дә исәпкә алып эш иттеләр. Билгеле шул чорның иҗтимагый-сәяси мохите шартларында күп кенә әдип, шагыйрьләребез зур хаталар да җибәргәннәрдер, дөреслектән тайпылыш та ясаганнардыр, әмма алар шул болгавыр заман корбаннары буларак та хөрмәткә лаеклар. Чөнки тоталитар хакимлек шартларында үз иҗат йөзләрен күпмедер саклап кала алу, әдәби осталыкларын үстерүгә мөмкинлек табу үзе каһарманлыкка тиң. Әйтергә кирәк бу чорда берсүзсез революцияне якладылар: берәүләр ике аралыкта бәргәләнде, икенчеләре урталыкта, ә өченчеләре исә большевиклар идеологиясен кабул итә алмыйча, мөһәҗирлеккә киттеләр.

1917-1941 еллар тарихы әдәби процессы үз эченә түбәндәге чорларны ала:

1. 1917-1921 – гражданнар сугышы чоры.
2. 1922-1929 – аякка бастыру чоры.
3. 1930-1937 – рекострукция чоры.
4. 1937-1941 - Бөек Ватан сугышы алды чоры.

**Гражданнар сугышы чорында татарлар**

1861 елда крепостное право бетерелсә дә 80 % крестьян халкы һаман да авыр шартларда яшәвен дәвам итә, җирләренең алпавытлар кулында калуы, эшчеләрнең авыр хәле 1905-1907 еллар инкыйлабына китерә, әмма барыбер үзгәрешләр күренми, халык арасында канәгатьсезлек үсә бара һәм шуның нәтиҗәсендә 1917 елның февралендә буржуаз революция бөтен җирне тетрәтә. Николай II тәхеттән ваз кичә. Халык үзгәрешләр көтә, әмма элекке сәясәт дәвам ителә: крестьяннарга җир бирелми, сугыш туктамый, милләтләргә хокуклар

бирелми. Шул арада «Крестьяннарга җир», «Эшчеләргә завод-фабрикалар», «Милләтләргә үзбилгеләнү хокукы» дигән алдагыч лозунглар белән халыкны үзләре белән ияртәләр. Шулай итеп, 1917 елның октябрендә илдә зур инкыйлаб була. Халык большевиклар програмасын үзенеке итеп ала, 1552 елдан соң беренче тапкыр үзебезчә яшәргә мөмкинлек туды, дип чын күңелдән куана. Әмма «оҗмах утравы» вәгъдә иткән большевиклар үзләрен патша заманнарына караганда да кырыс, каты тоталар. Илдә дүрт елга сузылган гражданнар сугышы башлана. Чөнки большевиклар хөкүмәтне беркем дә бүлешергә теләми.

М.Вахитов, М.Солтангалеев, Ш.Усманов, А.Шамов, К.Нәҗми, Һ.Такташ, М.Җәлил һ.б. әдипләре Гражданнар сугышында актив катнаша. Каләм ияләрен билгеле бер кысада тоту өчен язучыларның әдәби төркемнәре оештырыла. Милли большевистик матбугат тарату йөзеннән партия әдәбият, сәнгать әһелләре үз тирәсенә оештыра. 1918 елда «Чулпан» эш труппасы (Казан) оештырыла. Шуларның берсендә Г.Ибраһимов актив эшләп китә, һәм икенчесе Г.Камал җитәкчелегендә Үзәк мөселман хәрби «Кызыл армия» газетасы чыга башлый. Бу социалистик рухтагы язучыларны тәрбияләүче газета (К.Нәжми, Б. Рәхмәт).

Гражданнар сугышы чорында алгы сафка аеруча драматургия һәм поэзия чыга.

**Поэзия**

Бу елларда чынбарлыкны күтәренке итеп күрү һәм сурәтләү алгы планга чыга. Аны революцион романтизм дип атыйлар. Бу романтизм иҗат ысулын Совет чоры идеологиясенә буйсындыру, революцион романтизмны икенче төрле гыйсъянчылык белән бергә карыйлар.

Гражданнар сугышы чорында дөньяның ике капма-каршы лагерьга: акларга һәм кызылларга аерылуы поэзиядә ачык чагыла. Поэзия халыкны революцион рухта тәрбияләүче рухи коралга әверелә. Поэзиянең жанрлар системасына килгәндә бу чорда публицистик агитацион, сатирик, комик шигырьләр алга чыга. Мәхәббәт җырлары поэзия сәхнәсеннән чигенеп тора. Бу чор сатирик шигырьләре ике төргә бүленә: 1) шигырьләрдә исемнәре үк

эчтәлекле бәян итеп, 1 нче заттан сөйнәленә. Мәсәлән, «Буржуазия зары» «Кем идек, кем булдык?» шигырьләре.

2) тарих сәхнәсеннән бәреп төшерелгән сыйныфка атап язылган Фәтхи Бурнашның «Мөхәммәтҗан» шигыре шуңа ачык мисал булып тора.

Шагыйрьләрнең барысы да диярлек Вакытлы матбугат тирәсендә тупланалар: М.Гафури, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, Б.Рәхмәт, Һ.Такташ, М.Җәлил һ.б. шундый шагыйрьләрнең каләме нәкъ менә газета-журналларда чарлана.

Революцион көрәшкә шагыйрьләрнең мөнәсәбәте төрлечә була. Әйтик, М.Гафури, Ф.Бурнаш һ.б. поэзиясендә матур киләчәккә ышану, кан-коюга, көрәшкә чакыру идеясы көчле була. Революцион-романтик рух белән Шаехзадә Бабич (1895-1919) ижатында сугыш фаҗигасе «Кан шәүләләре», «Сугыш» шигырьләрендә чагылыш тапкан. Яктылыкка, тыныч тормышка сусау, Ш.Бабич иҗатының үзәген тәшкил итә. Яшь буын шагыйрьләре Шамун Фидан, Давыт Гобәйди, бу чорда кан коюны хуплаган иҗатлары белән характерлана.

Беренче урынга хезмәт темасы керә. Эшче хезмәтенә мәдхия укылу, аның көченә соклану: Н.Исәнбәт, Г.Камал, М.Гафури һ.б. иҗатларында ачык күзәтелә. 20 елның икенче яртысында Хәсән Туфанның татар поэзиясенә алып килгән яңалыгы Урал искизлары ике чор арасында башлана башлый. Бу бигрәк тә Бибиевлар поэмаларының композицион һәм тел-стиль үзенчәлегендә чагыла. Гыйсъянчылык күренеше Һ.Такташның «Нәләт», «Мәңгелек әкият», «Такташ үлде» һ.б. шигырьләрендә гыйсъянчы образ белән очрашабыз. Шул ук вакытта поэзиядә мифологик символларга киң урын бирелә. Һ.Такташның «Газраил», К.Тинчурин «Зар», М.Гафури «Күк җырчысы» һ.б. шундый әсәрләре атап китү дә күп мәгъ=лумат бирә.

1921 елгы ачлык фаҗигасе М.Гафури «Кеше ашаучылар», «Ачлык», Һ.Такташ «Җир уллары» трагедиясендә ачык чагыла. Аны сурәтләүдә шартлылык символларының көче сизелә. Иҗат методларына килгәндә яңа тормышны сурәтләүдә реализм, романтизм, модернизм, натурализм кебек иҗат ысуллары аралашып яши. Шулай ук гаилә, мәхәббәт темасы да зур урын алып тора. Һ.Такташ иҗатында символизм чагыла.

# 1917-1940 ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

## Г.Ибраһимов (1887-1938). М.Гафури (1860-1934) - тормыш юллары һәм иҗаты.

**Галимҗан Ибраһимов** татар совет әдәбиятына күпкырлы талант иясе буларак килеп керде. Аның Октябрь инкыйлабыннан соң классик язучы, татар совет әдәбиятының күренекле вәкиле, лидеры булып җитешүендә, һичшиксез, аның революциягә кадәрге чор иҗатының идея-эстетик үсеш югарылыгы, шул чорда тупланган иҗтимагый караш тәҗрибәсе зур роль уйный. Ул революциягә кадәр үк атаклы язучы гына түгел, яшәп килүче иҗтимагый стройга оппозициядә торган, аның белән килешмәүче көрәшче, журналист һәм фикер иясе булып танылa. Әмма җәмәгать эшлеклесе һәм революционер буларак әдип талантының тулаем ачылуы өчен бөтен кирәкле шартлар бары тик Октябрь революциясеннән соң гына барлыкка килә. Бу елларда ул көрәштәше Мулланур Вахитов белән кулга-кул тотынып эшкә керешә. Беренчеләрдән булып «Казан утлары»ның башлангычы булган «Безнең Юл» әдәби-политик журналын оештыручы һәм аның беренче редакторы була. Шул ук вакытта беренче татар совет педагогия журналына нигез салучы да була. «Татарстан» газетасының һәм «Коммунистический путь» журналларының беренче саннарын Г.Ибраһимовның эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Авторетитлы әдипнең бу фидакарьлеге көндәлек матбугат эшенә башка әдип һәм журналистларны туплау юнәлешендә дә уңай нәтиҗәләр бирә.

Г.Ибраһимов – совет чорында халык мәгарифенә нигез салучыларның да иң күренеклесе. Революциягә кадәр җитешкән укытучыларны совет платформасына күчереп, яңа тормыш төзүгә хезмәт иттерүдә, яңа педагогик кадрлар тәрбияләүдә дә аның хезмәте бик зур. Аның зирәк акыллы һәм кайгыртучынлыгы хәлиткеч әһәмияткә ия.

Г. Ибраһимовның тагын бер үзенчәлекле зур хезмәте – Гыйльми үзәк эшенә илнең танылган галимнәрен тартуда нигезле һәм күпкырлы багланышларга нигез салуда күренде. Нәтиҗәдә, М.Павлович, А.Самойлович,

В.Добрянский, И.Бороздин кебек атаклы тарихчы һәм әдәбият белгечләре Татарстан белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, бездә яңа буын фән эшлекеләре, гыйльми кадрлар хәзерләүгә җитди өлеш керттеләр. Әдипнең әдәбият, сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре, оештыру эшчәнлеге болар белән генә чикләнми әлбәттә. Ул татар совет культурасының формалашуына, үсешенә зур өлеш кертте. Һәм үзе дә фән, культура эшлеклесе буларак, бер Татарстанда гына түгел, ә бәлки бөтен ил күләмендә танылды.

Г.Ибраһимов гомеренең соңгы көненә кадәр татар әдәбиятына, мәдәниятенә тугрылыклы булып кала алды. Ул авырып китеп үзенең соңгы ун елын Кырым белән бәйләгән. Каты авыру аны аяктан ега, көндәлек иҗади эштән аера, Татарстаннан читтә яшәргә мәҗбүр итә. Ләкин язучы туган халкы, республика белән элемтәсен өзми, ул үзенең характеры, холкы белән һаман да көрәшче, ил, халык тормышы белән янып яшәүче булып кала.

Ялтада Ибраһимовның әдәби иҗат эше тукталмый. Ул «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның һәм «Безнең көннәр» романының яңа вариантларын яза. Сайланма әсәрләрен бастырып чыгарып зур эш башкара.

Г.Ибраһимов – репресиия корбаннарының берсе. 1937 елның көзендә Ялтада кулга алына, ә 1938 елның январенда Казанда Пеләтән төрмәсендә үлә. Ул татар совет әдәбиятына кабатланмас һәм мәртәбәле шәхес буларак кереп калды. Аның үз урыны, традицияләре, үзенчәлекле бай иҗади мәктәбе бар. Аның иҗаты онытылмас булып бүгенге көннәрдә дә бөек шәхесләребез тарафыннан өйрәнелә. Аның исемен мәңгеләштерү йөзеннән Татарстан фәннәр академиясе (Казан шәһәре) Г.Ибраһимов исемен йөртә. Аның иҗатын өйрәнүчеләрдән: Р.К.Ганиева, Д.Гильманов, Р.Минһаҗева һ.б.

Г.Ибраһимовның тормышы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге. 1917елдан соңгы әсәрләрендә сыйнфыйлык. “Безнең көннәр” романында XX йөз башы татар тормышының эпик колачлылыгы. “Тирән тамырлар”, “Кызыл чәчәкләр” әсәрләрендәге сыйнфый көрәш. Әсәрләрендәге ике планлылык.

“Казакъ кызы” романында Россия сәясәтенең казах тормышына йогынтысын, шуның нәтиҗәсе буларак күчмә кабиләләр арасындагы традицияләрнең җимерелүен күрсәтә.

Күренекле шагыйрь, публицист, прозаик **Мәҗит Гафури** 1880 елның Башкортостан республикасының Эстәрлетамак өязе Җилем-каран авылында укытучы гаиләсендә туа. Башта үз авылында, аннары күрше Үтәш авылы мәдрәсәсендә укый. 11 яшеннән эти-әнисен югалта. Уфадагы «Госмания» һәм Кышкы авылы мәдрәсәләренә укырга керергә тели. Ләкин керә алмый. Уралдагы чуен заводы төзелешендә балчык ташучы булып эшли башлый. 1898 елда Тройскийдагы «Рәсүлия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм шунда укый башлый. Рәмиевнең «Алтын приискасында» эшли, казакъ далаларында балалар укыта. Беренче әсәрләрен Тройский мәдрәсәсендә укыганда яза. «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» повесте (1902), «Себер тимер юлы», «Яшь гомерем» поэмаларын яза.

1905 елда Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлый. Бер елдан соң Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә күчә. 1909-1912 елларда Мәҗит Гафури язучылык эшенә ныклап керешеп китә. Шул чорларда 10 лап шигырь, 9 хикәя җыентыгы дөнья күрә. 1912-1917 елларда Уфадагы «Шәрыкъ» матбугатында корректор булып эшли. Совет чорында «Эшче» поэмасын, «Кара йөзләр», «Тормыш баскычлары», «Шагыйрьнең алтын приискасында» автобиографик әсәр булып языла.

Беренче әсәрләре XX йөз башына туры киләләр. Аның башлангыч чор иҗатында мәгърифәтчелек идеяләре гәүдәләнә: гыйлем, мәгърифәт үсешенә дан җырлана. Ул милләтнең артта калганлыгы, наданлыгы өчен борчыла.

1908-1913 еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр барлыкка килә. Хис-кичерешләргә күңел һәм фәлсәфи лирикага өстенлек ителә. Лирик геройларның күңел дөньясын романтик сурәтләп бирә. «Яфрак» (1909), «Таң яктысы», «Күңелсез минутлар» (1913). Милли хәяттәге тискәре күренешләргә тискәре күренешләргә надан, бозык, дин әһеләренә каршы сатирасын көчәйтә, оста аллегорик мәсәлче булып танылa. 30 мәсәл яза. Гаделсезлекне, усаллыкны

тәнкыйть итеп «Үгез белән бүре». «Сарыкны кем ошаган?», «Тавык белән үрдәк», «Эт белән куян» һ.б. мәсәлләр иҗат итә.

20 нче еллар ахыры 30 нчы еллар башында Мәҗит Гафуриның иске тормышны сурәтләүгә багышланган 3 зур әсәре дөнья күрә:

«Кара йөзләр» (1927),

«Тормыш баскычлары» (1928),

«Шагыйрьнең алтын приискасында» (1930).

Әлеге әсәрләр арасында аеруча популяры **«Кара йөзләр»** повесте.

Повестьның үзәк героинясы авылның иң чибәр, иң уңган кызы – Галимә.

Галимә үзе шикеле үк саф күңеле крестьян егете Закирне ярата, һәм аларның бергә сөйләшеп утырганнарын уйнаш кылдылар дип әйтеп, хәзрәт янына алып киләләр. Чынлыкта исә бу эшне оештыручылар, Галимә белән Закирнең мәхәббәтләреннән көнләшүчеләр була. Шундый чибәр кызның гади крестьян егете белән йөрүен яратмыйлар. Дин һәм шәригать исеме астында яшеренеп яшьләрнең мәхәббәтен трагедиягә әйләндерәләр. Әлеге вакыйга авыл халкын ике төркемгә бүлә:

1) дини фанатиклар, муллар, аларга иярүче томана халык;

2) икенче төркемгә бик аз гына кеше керә: хикәяләүче яшьүсмер шәкерт Гали, аның әти-әнисе һәм күгәрчен Сәлим.

Соңгысы хакында автор болай ди: «Бигрәк тә Күгәрчен Сәлим яхшы булып күренде, аның бу кечкенә гәүдәсе белән бу чаклы батырчылык итүенә, курыкмавына хәйран калдым. Мәдрәсәдә Күгәрчен Сәлим иң зирәк шәкертләрнең берсе була һәм шуның аркасында яшь булуга карамастан хәлфәгә әверелеп бара. Аңа каршы әйтергә шәкертләр генә түгел үзеннән зуррак хәлфәләр дә куркып торалар».

Соңрак бу герой Галине башка малайларның көлүеннән дә коткарып кала. Галинең әти-әнисе дә иске тормышка каршы протест белдерәләр, ләкин аларның бу каршы торулары әле көчсез була.

«Кара йөзләр» повестенда урталыкта калган геройлар да бар. Мәсәлән: фанатик, каты куллы, кырыс Фәхри. Ул Галимәнең атасы. Барлык халык

алдында кызын таяк белән кыйнап, аннан баш тартса да, хурлыкны бик авыр кичерә. Әмма тора-бара Фәхри үзенең хатасын аңлый һәм аның да дин әһелләренә ышанычы кими бара. Бу гаепләүләргә, хурлыкка Галимәнең нечкә күңеле түзми. Ул акылга җиңеләя башлый. Фәхринең соңгы ышанычы - ишаны, хәлфәләрне чакырып өшкертү була. Кунакларга туй табыны хәтле өстәл хәзерләнә, һәм менә бу вакыйгадан соң Гали шәкертнең дингә карата соңгы ышанычы да югала. Көз көне Гали мәдрәсәгә барудан баш тарта. Аның фикеренчә шәригать бик куркыныч әйбер. Ул кешеләрнең битләрен каралта, буен камчы белән кыйный, кулларын кисә. Көннәрдән бер көнне Галигә авылдан хат килә, анда Галимәнең вафаты турында сөйләнелә. Бу вакыйгалардан соң 30-35 еллар үтсә дә «иске тормышның миллионлаган корбаннарының берсе» Галимә апасы Галинең хәтереннән чыкмый.

Әлеге повесть язучының хыял җимеше түгел, реаль тормышта Галимәнең протиплары күп булган. Шуларның берсе Мәҗит Гафуриның бертуган апасы Сафия. Сафияне әтисе көчләп үзе яратмаган кешегә, авылларыннан 20-25 чакрым ераклыктагы бер Сакай авылы кешесенә - Шәриф дигән егеткә кияүгә бирә. Атасы бу эшне Сәбәгыйм исемле картның котыртуы буенча эшли. Бу вакыйга турында «Тәрҗемәи хәлем» автобиографик әсәрендә М.Гафури болай ди: «аның (Сафиянең) шул вакыттагы әрнүләре, почмакларга утырып елаулары, әледә күз алдымда тора. Шуннан соңгы күрешү вакытында апасының йөзе саргайган, зур күзләре тагын да зурайган, үзе ябыккан, хәлдән тайган кеше кыяфәтенә кергән була.

Күпмедер вакыттан соң Сафия үзенең туган өенә кайта. Озакка кунака кайтамы ул, әллә аерылып кайтамы автор монысын хәтерләмим, - ди. Әмма шунысы бар: апасы инде элеккеге нечкә күңелле, шат кыз булмый, авырып, түшәк өстенә ята һәм озак та үтми вафат була. Галимә шушы Сафиянең прототибы да инде.

**«Шагыйрьнең алтын приискасында».** 20-30 елларда язылган зур күләмле әсәрләреннән берсе. Төп геройлар җәйге яллар вакытында акча эшләү максаты белән Рәмиевләр приискасына юл тоткан мәдрәсә шәкертләре. Юлда

аларга төрле авылларга туктарга туры килә. Төрле милләт кешеләре белән очрашалар, автор аларның һәрберсен яратып сурәтли. Мәсәлән: Казах авылында шәкертләрне инде күптән күрмәгән ит белән сыйлыйлар. Икенче көнне хуҗа аларны күпмедер вакыт атта утыртып алып бара. Шәкертләр соңгы тиеннәрен бирергә теләгәч кире кага. Приискага барып җиткәннән бирле, авторның төп игътибары эшчеләр тормышын сурәтләүгә юнәлдерелә. Прииска хуҗасын автор ирония белән сурәтли, аеруча бу әсәрнең соңгы битләрендә күренә. Мәҗит Гафури Дәрдмәнднең шигырьләреннән өзекләр китерә-китерә аны тәнкыйть итә. Халык өчен бер тиен акчасын жәлләвен, пешекчедән бераз гына булса да каймак кызгануын, властька советлар килгәч, акчасын большевикларга бирергә мәҗбүр булуын һәм башкаларны әйтеп үтә, шуннан соң кире кайтара алмавын әйтә. Үзе дә шушы приискада эшләгәнлектән повестьтагы бөтен вакыйгаларны да Мәҗит Гафури йөрәге аша үткәреп тасвирлый. Әсәрдә шулай ук мөлаем образлар да шактый.

1925 елда М.Гафури үзенең бердәнбер драма әсәре булган «**Кызыл йолдыз**» драмасын иҗат итә. Анда гражданнар сугышыннан, тыныч тормышка күчә башлау да сурәтләнә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Гражданнар сугышы һәм аннан соңгы шагыйрьләрнең эзләнүләре.
2) Яңа образлар тудырырга омтылыш.
3) Бу чор әдәбиятының үзенчәлекләре.
4) Әдәбиятның социаль заказлар үти башлавы.
5) Сыйнфыйлык төшенчәсенең әдәбиятка тәэсире.
6) Мәҗит Гафуриның 20 нче еллар лирикасы. «Эшче» поэмасы.
7) М.Гафуриның «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында». Әсәрләрдә чор тенденцияләре.
8) Г.Ибраһимов иҗатында социалогик метод. «Кызыл чәчәкләр турында хикәя».

9) Г.Ибраһимов. «Адәмнәр» повесте. Натуралистик сурәтләүдә ачлык фаҗигасен тасвирлау.

10) Г.Ибраһимов. «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы».

**Гамәли биремнәр:**

1. Г.Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты.

2. Октябрь революциясеннән соң чор иҗаты: «Казакъ кызы» романы. әсәрдә гореф-гадәтләрнең бирелеше.

3. «Кызыл чәчәкләр» повесте. Әсәрдәге төп образларга характеристика

4. «Адәмнәр» повестенда ачлык фаҗигасы тасвирлары.

5. «Тирән тамырлар», «Яңа кешеләр», «Татар хатыны ниләр күрми». «Безнең көннәр» әсәрләрендә чор тенденцияләре. Образларга характеристика.

**Глоссарий:** **г**ыйсьянчылык – (гарәпчә “гыйсьян” – буйсынмау, баш күтәрү, фетнә, бунт) – XX йөз башы, бигрәк тә 20 еллар татар романтик әдәбиятында дин-шәригать кануннарына, иске тормыш тәртипләренә, социаль явызлыкка каршы ярсып баш күтәрү, аларны инкяр итү.

**Әдәбият:**


1. Г.Ибраһимов мирасы һәм хәзерге заман: фәнни гамәли конференция материаллары ( 5март,2007) – Яр Чаллы: НГПИ, 2007.

2. Галиуллин Ф. Әле без туганчы...– Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.

3. «Сәлам сиңа тормыш» // Татар поэзиясе.

4. Заһидуллина Д. Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 274 б.

# ТЕМА № 2
# Һ.ТАКТАШ (1901-1931): МӘҢГЕЛЕК ҖЫРЧЫСЫ.
# Ш.УСМАНОВ (1898-1937) ИҖАТЫ.

**Аннотация:** Большевиклар идеологиясенең әдәбият үсешенә тискәре йогынтысы. Вульгар социологизм чәчәк ату. Әдәби иҗат процессын чынбарлыкны пассив фиксацияләүгә кайтарып калдыру.

**Мөһим сүзләр:** Революция, сыйнфыйлык, пролетар әдәбият, футуризм, имажинизм.

Шагыйрь, драматург, җәмәгать эшлеклесе **Һади Такташ** 1901 нче елның 1 нче гыйнваренда Мордва республикасының Тарбиевко районы, Сыркыды авылында урта хәлле ишле гаиләдә дөньяга килә. Башта үз авылында аннан соң 30 чакрымдагы Пешлә мәдрәсәсендә җәдитчә белем ала. Зур гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, әтисе Хәйрулла абзый, улларын читкә эшкә җибәрергә мәҗбүр була.

Олуг Төркестан газетасында мәдәни темага мәкаләләр, «Төркестан сахраларында» беренче шигырен яза (1908). Бик күп галимнәр аның турында өйрәнәләр: Миләүшә Хәбетдинова, Тәлгать Галиуллиннар бу шәхес иҗатын өйрәнгәндә мөһим чорны күрсәтеп узалар. Алар аның иҗатын берничә чорга бүлеп өйрәңәләр:

**1) Бохара чоры (1916-1918).** Бу чорда ул «Газраилләр», «Караңгы төннәрдә». «Төркестан сахраларында» кебек дини-фәлсәфи эчтәлекле романтик шигырьләрен иҗат итә. Автор үзен җәдитче милләт кадиме (слуга нации) итеп күрсәтә. «Олуг Төркестан» газетасында дөнья күргән 3 мәкаләсе талантлы журналист икәнен раслый.

Бу чор шигъриятендә Такташ иҗатының киләчәк программасы чагыла. «Газраилләр» шигырендә империалистик сугыш һәр яклап тәнкыйть ителә. Халык өчен зур хәсрәткә әверелүенә басым ясала. Шагыйрьнең сугышка каршы протесты мистик формада бирелә, аның уңай герое фәрештә. Бу дөньяда

ярдәмсез, көчсез. Шуңа автор аны канлы җирне ташлап, бәхет иленә качарга өнди:

«Фәрештәкәй <u>кач</u> бу илдән,

Монда дәһшәт, монда үлем

Монда патша газраилләр!»

*«Кара төннәр» (1916)шигыре:*

«Фәхеш җир кулында *мөмкин*

*Еланнар* ояласын инде»… Әлеге шигырь мистика һәм өметсезлек белән сугарылган. Шагыйрь бу дөньяны фәһим дип атый, һәм укучыны әлеге дөньядан китәргә, күккә ашарга чакыра.

**2) Сыркыды чоры (1918-1919**). 1918 елның көзендә Такташ туган авылы Сыркыдыга кайта. Китапханә мөдире булып эшли. Иҗат эшен актив дәвам итә. Бу чор шигырьләрендә фикер тирәнлеге, уй хөрлеге, халыкчанлык күзгә ташлана. Автор бу чорда җәмгыятьне бары инкыйлаб юлы белән генә үзгәртеп була дигән фикерне яклый. «Үтерелгән пәйгамбәр» (1918), «Күктән сөрелгәннәр» (1918) шигырендә җирдәге мәһшәргә түзә алмагач, фәрештә кыз күк алласы янына барып бу хәлләргә карата ризасызлыгын белдерә: «*бөтен җирдә коллык, күз яше һәм кан*» дип таләп итә. Күк алласы моның өчен аны күктән сөрә, җир зинданына бикли. Озак еллардан соң күк алласы газраилен бу фәрештәнең җанын алырга дип җиргә җибәрә. Газраил кызның гүзәллеген күреп, гашыйк була. Газраил мәхәббәте – ул үлем. Ул бер тиюгә фәрештәнең җаны чыга. Кайгыдан Газраил күк патшасына каршы чыга. Бу әсәр дөреслекне күрсәтеп, коллыкка каршы адәм балаларын көрәшкә күтәрелүен белдерә.

**3) Ташкент чоры (1921-1922).** Идел-Урал буйларында хөкем сөргән ачлык Һади Такташны ипиле Ташкентка алып килә. «Белем йорты» дигән журналда җаваплы сәркатип, аннан соң мөгаллим булып эшли. Ул туган төбәгендәге ачлык фаҗигасенә карата әрнүләрен белдереп, «Ачлык патша» (1921), «Күләгәләр» (1922) дигән шигырьләрен яза. 1921 елның июнендә бик кыска вакыт эчендә «Җир уллары» дигән беренче драматик поэманы иҗат итә. Монда да үлем, ачлык кылычының бөтен илне үз әсирлегендә тотуы үзәккә

куела. Кеше үтерү көрәш түгел, ирек, бәхет китерә алмый. Әмма ирек өчен туганын суючы Кабиль бигрәк тискәре образга әйләндерелми. Кабиль ике яссылыкта күзәтелә: беренчесе, мөмкинлеге бик чикләнгән ниндидер зур идеал, икенчесе, ил өстендәге революция дулкынын гәүдәләндерә. Әсәр үзәгендә Кабиль һәм аның яраткан кызы Әкълимә тора. Төп сюжет аларның трагик мәхәббәте. Әкълимә дини богаулардан котыла алмаса да, Кабильгә булган мәхәббәте белән рухланып, аңа ахырга кадәр тугрылыклы шәхес булып кала. Гомумән алганда, авторның Ташкент чоры гыйчьянчылык ялкыны, көрәш рухы белән сугарылган. Бу дәвердә ул гаделлекне иҗтимагый тигезлекне яклап «Онытылган аң», «Күләгәләр», «Таң кызы», «Урман кызы» кебек шигъри әсәрләрен иҗат итә.

**1923 ел рухи азатлыкка омтылган чор**. Бу чорда Такташ иҗтимагый тормыш агымына каршы чыга, гыйсъянчылык поэзиясен алга сөрә. «Такташ үлде». (*«Гыйсъян» гарәп сүзе, баш күтәрү дигәнне аңлата, романтизм юнәлешенең бер агымы).* Совет чорында бунтарь романтизм дип йөртелде. «Гыйсъян» каһарман яшәеш кануннарына аллага, дин, шәригатькә каршы күтәрелгән шәхес. Аның өчен иң беренче урында рухи хөрлек, азатлык. Ул үзен Алла белән тиңли. 20 нче елларда гыйсъянчылык яңа көч белән кабынып китә. Революцион романтизмга каршы төшә: Х.Туфан, Ф.Бурнаш һ.б. иҗатында күренә.

Бу елларда гыйсъянчылык җанланып китүенең берничә сәбәбе бар:

1) бу чор иҗади яшьләр кочакка сыймаганны колачларга омтылдылар. Гыйсъянчылык аларның романтик хыялларын ачып бирде;

2) космизм, гомумдөнья планетар революцион хәрәкәтне югары куеп тасвирларга кирәк булды.

**4) Казан чоры (1924-1931).** Такташ татар театрында суфлер булып эшли. «Азат хатын» журналында эшли. Бу дәвер иҗатында Ленин үлеменә мәтам (кайгы) рәвешендә язылган «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы белән үтеп керә.

Мәхәббәткә, гаилә тормышына, яшьлек ямена багышланган «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай», «Ак чәчәкләр» әсәрен иҗат итә. «Мәхәббәт

тәүбәсе» (1927) поэмасында үзәк образлар – Зөбәйдә белән Мәхмүд. Аларның мәхәббәт маҗаралары, яныып яратышулары, аннары алданулары, поэманың сюжетын тәшкил итә.

Шагыйрь мәхәббәткә бәйле шәхеснең җавалылыгы мәсьәләсен күтәрә. Әсәр яшьлек һәм мәхәббәтнең кабатланмас бер мизгел булуын һәм кадерен акыллы һәм мәгънәле итеп яшәү кирәклегенә ишарә ясый. Шагыйрь яшьләргә мәхәббәт уен түгеллеген, аның ирләр, бигрәк тә ата буласы кешеләр өчен җаваплылыгын, бала, анасының изгелеген күрсәтә.

**«Урман кызы»** (1922) романтик рухлы шигырь. Әсәр үзенең камиллеге, тәэсирлеге, серлелеге белән таң калдыра. Лирик герой бәхет эзләргә чыккан юлчы – шагыйрь үзе буларак күз алдына баса. Поэманың беренче юлларында ук без Әминә исемле кыз белән танышабыз. Шаян, матур, оялчан, серле ул. Очкынлы күзләренең көче шагыйрьне телсез итә. Әмма ул бик яшь, күзләрендә мәхәббәт билгесе дә юк. Анда дөньяга соклану гына бар. Әминә бу матурлыгы өчен табигатькә бурычлы. Шагыйрьгә иртән очраганга күрә ул – таң кызы. Бу шигырьгә Җәүдәт Фәйзи көй яза. «Урман кызы» исеме белән җыр тарала.

Шагыйрьнең иҗаты «**Киләчәккә хатлар**» поэмасы белән тәмамлана. Әсәрен автор 1,2,3 хат дип бүлекләргә бүлә. Һәр хатта 1-2 очрак алына, шул очрак вакыйга үзәгенә 1-2 персонаж куела.

**1 нче хатта** шагыйрь бу хатны язарга этәргән сәбәпләрне атый. Күп баш ваткач бу хатны язарга мәҗбүр иткән хисләр – чын дөреслек, ди.

**2 нче хатта** Такташ сыйнфый көрәшнең газаплы һәм бик авыр булуына басым ясый. Мохтар карт образын үзәккә куя. Бу хатта Мохтар карт психологиясендәге икеләнүләре сурәтләнә. Күмәклек, бердәмлек, колхозлану чоры күзәтелә.

**3 нче хатта** социалистик хезмәт кешесенең психологиясенең ничек үзгәрүен күрсәтә. Төп фикер илдә барган колхозлашу чоры каршылыклы һәм авыр, ләкин бу эш гамәлләр бары тик яхшы нияттән эшләгәнгә кешеләр күмәкләшүгә баралар.

«Киләчәккә хатлар» әсәре 30 елларның шигъри документы буларак үз әһәмиятен югалтмый. Тарихны дөрес итеп аңларга ярдәм итә.

**«Камил» (1929)** колхоз оештыру, күмәкләштерү темасына багышлана. Сыйнфый көрәш үзәккә куела. Автор идеалын чагылдыручылар Камил, Рөстәм. Камил яңа тормыш төзүчеләр янында. Әтисе Габдулла, абыйсы – Сөләйман капма-каршы якта. Алар колхоз оештырырга кайткан Рөстәмне үтерергә баралар. Әйтеп үткәнчә, Һади Такташ иҗаты бай һәм күп яклы. Ул – театр һәм драматургия үсеше тарихында тирән эз калдырган әсәрләр авторы да, чор таләбен тирән тойган үткен фикерле публицист, тәнкыйтьче һәм журналист та, үзенчәлекле прозаик та. Әмма барыннан да бигрәк ул – шагыйрь. Аны – яңа матурлык җырчысын – татар халкы үзенең халык язучысы итеп таныды, әсәрләре татар әдәбиятының алтын хәзинәсендә урын алды. Әдәбият белемендә аңа багышланган күп хезмәтләр дөнья күрде.

**«Җир уллары» трагедиясе** Кабил һәм Хәүва турындагы дини легенданга нигезләнә. Алар турында әсәр язу идеясе Такташта күптән туа. Ул хәтта алар хакында өйрәнчек әсәрдә язып карый. Әмма соңыннан күпкә катлаулырак әсәр – «Җир уллары» трагедиясен яза. Трагедиядәге төп образлар Идея, Кабил, Хәүва, аларның сеңлесе Әкълимә, Алла һәм аның кануннары, фәрештәләр һәм башкалар. Элегрәк бу әсәр аллага һәм иске тәртипләргә каршы язылган диелсә, бүгенге көндә кайбер галимнәр башкача фикер йөртәләр. Әлеге әсәрендә Такташ кануннарның кешене – җир улларын рухи изүен һәм рухи зольмәткә каршы кешедә акылның уянуын, көрәш башлануын көчле драматизм, мифологик монументальлек белән, югары пафослы итеп сурәтләде. Биредә дә шагыйрь әлеге образларга элек салынган мәгънәви йөкләмәләрне үзенчә үзгәртә, аларга шул чордагы революцион социалистик атмосфера тәэсирендә үзенчә аңлатма бирә.

Әсәрнең эчтәлеге дингә каршы көрәш мотивы белән генә чикләнми. Трагедиядә шундый ук көчле пафос (рух) белән сурәтләнгән һәм киң урын бирелгән мәсьәлә – ул кешенең физик һәм рухи коллыкка каршы көрәшкә күтәрелү идеясе. Дини хорафатлар белән көрәш мотивы вакытлар үтү белән

үзенең кискенлеген югалтырга мөмкин, ә менә рухи халәткә каршы баш күтәрү идеясе, акыл, мәхәббәт һәм иманның уянуы исә - «мәңгелек» проблемалардан. Әсәрнең «Җир уллары» дип аталуы да шуңа бәйле. Сүз әсәрдә җир улларының фаҗигасе һәм шул фаҗигадән котылу юллары турында бара. Беренче күренешләрдә җирдәге «җәһәннәм», авыр шартларда яшәргә дучар ителгән халык тормышы гомуми рәвештәрәк күренеп кала һәм шундый тормышта яшәүнең сәбәпләре күрсәтелә. Идея фикеренчә, ул сәбәпләр – «котырган юлбасарлар иркенә бирелеп яшәүдә», вәхши Алла кануннарына буйсынуда, коллар булып яшәүдә.

Керештә гомумән халык фаҗигасе күрсәтелсә, төп күренешләрдә Кабил, Әкълимә, Хәүва образлары аша шәхес фаҗигасе, шәхеснең рухи трагедиясе беренче планга чыга. Әсәр аллага баш күтәргән Кабилнең протест йөзеннән үз-үзен үтерүе белән тәмамланса да, бу хәл «хөкеме мәкерләр, хәйләләр белән тулы» алланың җиңүен аңлатмый. Әкълимә һәм Кабилнең саф мәхәббәтләре, аларның аллага каршы күтәрелүләре күк патшалыгын какшата, җиргә акылның, мәхәббәтнең, иманның уянуын хәбәр итә. Кабил, Әкълимә үлеме мисалында җир балалары элеккечә яшәргә мөмкин түгеллеген аңлыйлар. Акыл, иман, мәхәббәтнең уянуы һич тә Алла кануннары белән сыеша алмый. Шуңа да трагедия көрәш рухлы сүзләр белән, Идеянең Кабил гәүдәсе янында сөйләгән «Бетмәс канлы көрәш Кабилнең үлүе белән» дигән анты белән тәмамлана. Идея – ул Такташ яшәгән чор идеологиясе. Кабил – шул идеология тәэсирендә үз кыйбласын югалткан кеше. Ул үзе турында болай ди:

… Мәңгелек михнәт күрәм
Каядыр очмак булам да,
Юл табалмый тилмерәм.

Әлбәттә, мондый хәләттә идеологиягә Кабилне алдау кыен түгел. Идея турында сөйләгәндә Такташ аны ут чәчәге дип атый. Берничә тапкыр Кабил янына аның качып-посып килгәне ассызыклана. Димәк, аның намусы чиста түгел. Әсәр ахырында Идея тәэсирендә Кабил җинаять кыла һәм үз-үзен үтерә.

**Язучы, драматург һәм җәмгыять эшлеклесе Ш.Усмановның тормыш һәм көрәш юлы.** Революциягә һәм әдәбиятка мөнәсәбәте. “Канлы көннәрдә”, “Ил кызы”, “Легион юлы” әсәрләрендә гражданнар сугышы һәм кеше язмышы мәсьәләләре.

Шамил Усманов үзе Татарстан якларыннан булмаса да (ул 1898 елның 26 октябрендә хәзерге Пенза өлкәсе Кузнецк районыныда дөньяга килә) татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә.

Шамил Усманов повестьлар («Легион юлы» «Памирдан радио»), хикәяләр («Гает корбаны», «Ил кызы», Краском мәхәббәте» һәм пьесаалар авторы («Канлы көннәрдә». «Бай кызы» һ.б.). Әдәби мирасының күләме шактый булса да, язу аның төп эше түгел. Ул нче һәм икенче тататр бригадаларының комиссары. Әмма бу бригадалар әзер килеш аның җитәкчелегенә тапшырылмаганнар. Шамил Усманов аларны төзү өчен рөхсәт артыннан үзе йөри. Командаларны үзе таба, киемнәрне, коралларны үзе юллый, сугышчыларны да үзе җыя. Бүгенге вакытта әлеге татар бригадалары турында фәнни хезмәтләр языла, ә бу эшне башкарган ваыктта Шамил Усмановка нибары 20 яшь була.

Аның язучылык эшенә кереп китүе, Шамил Усмановның хәрби хезмәте белән бәйле. Ул татар бригада, татар полкларында матур әдәбиятка мохтаҗлык барлыгын тоя һәм политбюро начальнигы булган вакытта үз тирәсенә күп кенә язучыларны туплый. Шул ук вакытта үзе дә язучылык эшенә алына. Әдәби жанр итеп ул үзенә пьесаларны сайлый. Сәбәбе гражданнар сугышы елларында драматургия иң үтемле чарага әверелә.

Фронтлардан яңа пьесалар сорап бер-бер артлы хатлар килә. Нәтиҗәдә 1919 елда «Канлы көннәрдә»исемле беренче пьесасын яза. Аннары «Беренче адым», «Бай кызы» пьесалары дөнья күрә. Беренче пьесаларында кайбер җитешсезлекләр күренә әле. Мәсәлән, «Канлы көннәрдә» әсәрендә психологик анализга игътибар җитми. Моны вакыт тарлыгы белән дә аңлатып булла. Автор анны Оренбургны дошманнан азат иткәннән соң 1 төн эчендә язып чыга. Үзәк песонажлар Камил белән Хәмит революцион көрәшкә бирелгәннәр, яңа

тормыш төзү өчен актив көрәш идеясын чагылдыралара. Әмма автор аларны индивидуаль шәхес буларак тасвирламый. Шул ук хәл Йосыф образында да чагыла. Йосыф башта офицер була, кызылларны күрә алмый, әмма каты яраланганнан соң аның фикерләре кинәт үзгәрә. Бу карашлар үзгәреше ничек барлыкка килгән – укучыга аңлашылмый кала. Ләкин кимчелекләргә карамастан гражданнар сугышы елларында пьеса сәхнәдән төшми. Гражданнар сугышы тәмамлангәннан соң Шамил Усманов иҗатында да үзгәрешләр күренә. Бу вакытта матбугатта мәхәббәт, гаилә турында бәхәсләр алып барыла. Шамил Усманов та алардан читә калмый. Мәсәлән, «Ил кызы», «Краском мәхәббәте» хикәяләрендә, мәхәббәт, хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны турында сүз бара. «Ил кызы» хикәясендә бер төркем кызыл сугышчылар – Хатип, Хәбир, Вәли, Тәүфикъ, Әхмәт татар кызларының язмышы турында кызу бәхәс алып баралар. Аларны татар кызларының олы максатлар белән яши алмаганлыклары борчый. Татар кызлары әле иннек белән кершәннән башка нәрсәләр турында уйларлык хәлгә килмәгәннәр. Безнең ниятләрне аңлап авыр көрәш сафында безгә мәгънәви таяныч булла алырлык татар кызы әле дөньяга тумаган, һәм күп тә үтми геройлар үзләре хыялланган татар кызын очраталар. Рауза өчен мәхәббәт кешене тыныч рәхәт тормышка чакыручы көн түгел, ә авыр көрәшкә рухландыручы хис.

Шамил Усманов иҗатында төп урынны алган әсәр – «Легион юлы». Повесть шактый озак еллар дәвамында языла – 1921-1935. автор аның өстендә кабат-кабат эшли. Үзе үк русчага тәрҗемә итеп бастыра. Өзекләрен Максим Горькийга җибәрә. Шуннан соң алар күп мәртәбә хат алышалар, берничә тапкыр очрашалар. Әсәр реалистик планда язылган. Төп тема – яхшы коралланган дошман белән авыр көрәш алып баручы интеранациональ легион отрядының көндәлек тормышын сурәтләү. Бу легионның тормышын автор табигый, кырыс рәвештә катлаулы тасвирлый. Әсәрдә үзәк геройда, катлаулы сюжет сызыгы да күренми, чөнки Шамил Усмановны аерым шәхес язмышы түгел, ә ил, масса язмышы кызыксындыра, һәм күп вакыйгаларның төрле персонажларның бер-бер артлы алыштырылып торуы аркасында укучы әлеге

массаны күз алдына китерә ала. Барлык вакыйгалар да документаль төгәллек белән бирелә, әдәби фантазиягә бөтенләй урын калмаган диярлек. Автор үзе исә вакыйгаларда турыдан-туры катнашмый. Вакыты-вакыты белән хәтта сюжеттан чыгып та тора. Чөнки үз фикерен әйтүдән бигрәк сугышның реаль картинасын, реаль вакыйгаларын күрсәтү әһәмиятле. Әсәр геройлары да Шамил Усмановны иң элек сугышчы буларак кызыксындыра.

«**Памирдан радио**» (1925). Алдагасыннан аермалы буларак монда автор маҗара жанрына мөрәҗәгать итә, үзәк герой Җаббарны гадәттән тыш ситуациягә куя. Профессор Габрахман Сәгъди әлеге әсәрне хыялый авантюр повесть дип атады. Үзәк геройның чиктән тыш батырлыгын, ханның 500 кешелек 1000 кешелек гаскәрен кырык салучы үзәк герой Таһирның батырлыгы белән чагыштырды. Шәриф Камал исә әсәргә реалистик ноктадан чыгып бәя бирде һәм Җаббарның совет шартларында правокатор Кукушкин_Осиповка каршы көрәшә алмыйча чит илгә чыгып китүен психология законнарына берничек тә сыймый диде. Нәтиҗәдә повестьның бөтенлеге какшый дип әйтте. Флүн Мусин һ.б. галимнәр фикерләренчә әсәргә ике төле караш, аның ике төрле стильдә язылуы белән аңлатыла. 1 енчесе – Җаббарның совет илендәге тормышы реалистик планда сурәтләнә, икенчесе – чит илдә һәм аннан әйләнеп кайтканнан соңгы вакыйгалар романтик стильдә автор автор фантазиясенә буйсындырылып язылган.

Шамил Усмановның әдәби иҗаты «Кичеккән фәрман» (приказ) пьесасы белән тәмамлана. Бу әсәр өстендә дә автор кат-кат эшли. 1932 елда язып тәмамлый, русчага тәрҗемә итеп Мәскәүгә иң яхшы пьесалар конкурсына җибәрә. Пьеса анда югары бәя алса да, автор гомеренең соңгы көннәренә хәтле аны камилләштерә. Аның сюжетына, образлар системасына үзгәрешләр кертә. Пьеса чынбарлыктагы вакыйгаларга нигезләнгән, үзәктә катлаулы тормыш процессы. Колчак ягында сугышкан башкорт хөкүмәтенең ничек итеп совет ягына чыгуы сурәтләнә. хәтта геройларның прототиплары да булла, мәсәлән, үзәк герой Харис Садыйков милли буржуаз башкорт хокүмәтенең хәрби җитәкчесе, Зәки Вәлиди әсәрдәге генераль Чулпанов чынбарлыкта

отставкадагы подполковник Акчулпанов. Төп геройны автор җиңел юлдан китеп бөтен яктан да тискәре рәвештә сурәтли.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Һади Такташ иҗатының башлангыч чоры. Гыйсъянчылык.

2) Һ.Такташ иҗатында совет чоры идеологиясе чагылышы. «Җир уллары» трагедиясе.

3) Һ.Такташ драматургиясе. «Камил», «Күмелгән кораллар».

4) Ш.Усманов – драматург. «Канлы көннәрдә», «Беренче адым», «Бай кызы». «Краском мәхәббәте», «Ил кызы».

**Гамәли биремнәр:**

1. Һади Такташ тормыш юлы һәм иҗаты.
2. Башлангыч чор иҗаты (1916-1923). Дини мифологик һәм космик образларга мөрәҗәгать итүе. «Газраиләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Җир уллары» трагедиясе. Әсәрдә урын һәм ике төле вакыт.
3. Тормыш гаделсезлеге белән килешмәүче гыйсъянчы герой. «Гыйсъян», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Такташ үлде».
4. Мәхәббәт хисләрен чагылдыруда романтик шартлылык, символлар. «Таң кызы», «Урман кызы», «Зәңгәр күз».
5. Иҗатының II чорына хас төп үзенчәлекләре (1924-1931). «Сыркыды авылы», «Әйдә энем», «Ак чәчәкләр».
6. «Алсу» поэмасында яңа чор хатын-кызының идеаль сурәтен эчке һәм тышкы матурлыгын ачу осталыгы.
7. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында яшьлек һәм мәхәббәт хисләренә дан җырлау.
8. «Киләчәккә хатлар» поэмасының үзенчәлекле формасы.
9. «Камил» драмасы.
10. Тормыш юлына күзәтү.
11. Шамил Усмановның гражданнар сугышы чоры иҗаты.

12. Хикәяләре. «Легион юлы», «Памирдан радио»

**Глоссарий: в**ульгар социологизм – марксизм идеологиясенең сыйнфыйлыгы мәсьәләсен үтә берьяклы аңлатудан килеп чыккан һәм тарихи-әдәби процессны гадиләштерүгә, схематизмга китергән карашлар системасы.

**Әдәбият:**

1. Бәйрәмова Ф. Мишәрнең бөек улы: фәнни-публицистик язмалар. Драматургия. – Казан: “Аяз” нәшр.,2001.

**2.** Әхмәдуллин А. Дөреслеккә ирешү юлында – Казан: Татар.кит.нәшр.,1993. – 168 б.

## ТЕМА № 3
## К.ТИНЧУРИН (1887-1938) ИҖАТЫ

**Аннотация**: Октябрь инкыйлабы һәм халык язмышы. Иҗтимагый-икътисади тормыштагы, милли – дини өлкәләрдәге үзгәрешләрнең кеше рухына ясаган тәэсире. Гражданнар сугышы һәм әдәбият. Кешелеклелек һәм сыйнфыйлык төшенчәләренең үзара мөнәсәбәте.

**Мөһим сүзләр:**

Сугыш чоры, тыл, контраст сыйфатлар, яшәү һәм үлем, батырлык.

**Кәрим Тинчурин.**

1. Тормыш юлы. Башлангыч чор иҗаты. Зәңгәр шәл, Ил, Кандыр буе әсәрләре.

2. Башлангыч чор иҗаты.

3. 20-30 еллар иҗаты.

а) драматург, б) прозаик.

Драматург, журналист, хикәяләр остазы, күренекле режиссер һәм артист Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә Пенза өлкәсе Аккүл (Таракан) авылында ишле гаиләдә дөньяга килә. Башлангыч белемне күрше

авыл мәдрәсәсендә алгач, 1900 елда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга килә. 1905 елгы революция дулкыны мәдрәсәгә дә үтеп керә, 87 шәкерт белән бергә ул мәдрәсәдән чыгарыла. Соңыннан бу хәлләргә нигезләнеп, 1936 елда ул «Мәрҗәннәр» дигән хикәяләр, новеллар яза.

«Мөназарә»(бәхилләшү) (1906) комедиясе языла.

1910 елда ул Габдулла Кариев җитәкчелегендәге беренче татар труппасы «Сәйяр» гә артист булып алына. Октябрь революциясеннән соң бу труппага җитәкче итеп билгеләнә.1922 елның 8 ноябрендә Казанда «Кызыл Октябрь» исемендәге Татар дәүләт театры ачыла. Баш режиссеры итеп Кәрим Тинчурин билгеләнә. (Хәзер ул Г.Камал исемендәге театр). Ул оста прозаик, хикәяче дә.

Юмористик һәм сатирик хикәяләре 1917 елга кадәр басылган. 1926 елда аңа Татарстанның Атказанган артисты дигән исем бирелә. Кәрим Тинчурин 30 еллардагы репрессия корабаннарының берсе. 50 яше тулган бәйрәмнәрнең икенче көненә 1937 елның 16 сентябрендә аны кулга алалар. Милләтчелектә (япон шпионы булуда гаепләп) 1937 елның ноябрендә махсус киңәшмә аны үлем җәзасына хөкем итә, һәм 15 ноябрь төнге 1сәгать 50 минутта атып үтерелә. Кабере якынча Казанның Архангель зиратында булырга кирәк.

1955 елда шәхес культы фаш ителгәч Кәрим Тинчурин исеме аклана, әсәрләре халыкка кире кайтарыла.

Иҗаты: Кәрим Тинчуринның иҗатын ике чорга бүлеп карыйлар:

*Иҗади мирасы*: 12 комедия, 5 драма, 4 музыкаль драма, 1 трагедия, 4 әсәре башка авторлар белән берлектә язылган һәм күп кенә хикәяләре барлыгы билгеле. Аның иҗатын ике төркемгә бүлеп карыйлар: 1) 1910-1917 еллар – хикәяләр «Беренче чәчәкләр» драмасы (1913), «Назлы кияү» (1916), «Соңгы сәлам» пьесасы (1917); 2) 1918-1937 еллар – «Йосыф белән Зөләйха», «Сакла шартламасын», «Тутый кош» (1918), «Казан сөлгесе» (1922) драмасы, «Американ» драмасы (1923), «Кандыр буе», «Ил», (1923), «Мәрҗәннәр» исемле хикәяләр, новелалар тезмәсе (1935-37).

Башлангыч чор иҗаты дип, без, нигездә Октябрьгә кадәрге язылган әсәрләрен кертеп карыйбыз.

Бу чор ижаты яшь Кәримнең әдәби-эстетик карашларын, бөтен киләчәк ижат программасын чагылдыралар. Кәрим Тинчуринның башлангыч чор ижатына беренчедән, ижтимагый-сәяси партияләр йогынтысы, рус-Аурупа әдәби-фәлсәфи фикере һәм татар әдәбиятының күп гасырлык традицияләре зур йогынты ясыйлар (Гареб, Шәрык).

19 гасыр ахырында халыклашкан мәгърифәтчелек реализмы, мәгърифәтчелек романтизмы, әдәби-эстетик принциплары XX гасыр башы тәнкыйди реализмы, 10 еллар романтизмы барысы да Кәрим Тинчурин ижатында очраша, синтезлаша. Моңа мисал итеп «Беренче чәчәкләр» драмасын әйтеп үтәргә мөмкин.

**«Беренче чәчәкләр»** - драманың нигезендә халыкка хезмәт итү идеясы ята. Әсәрнең геройлары бер үк мәдрәсәдә күп еллар буена укып ятучы шәкертләр. Авторның симпатиясы Хәмит ягында. Ул мәдрәсәдәге белем бирү системасыннан канәгать түгел, университетка керергә хыяллана, тормышының максаты югары белем алып, доктор булу, яки шул юлда вафат булу. Хәмит кебек искелеккә каршы баш күтәргән шәкертләр - беренче чәчәкләр ул. Ләкин төп геройның үзе үк әйтүенчә, беренче чәчәкләр бик сөйкемле булалар, әмма никадәр сакласаң да, бик тиз шиңәләр. Хәмитләргә дә кырау төшә. Беренчедән, зур тырышлык нәтиҗәсендәуниверситетта укыса да взнос акчасын вакытында түләмәүне сәбәп итеп аны университеттан куарга торалар, икенчедән күп еллар буена кысан мәдрәсәләрдә яшәгәнлектән аның сәламәтлеге какшаган, үпкәсе авыру.

«Я, нинди каһәрле дөнья бу? Албасты басты төсле басып тын алырга ирек бирми. Сәгать саен яңа хәбәр, яңа куркыныч, яңа авырлык. Хәмит кебек сулган чәчәкләр әсәрдә берәү генә түгел. Габделхак та, Сөләйманов та вакытыннан алда кабергә керәләр.

Әсәрдә тискәре персонаж Хәмитнең сабакташы Хәкимҗан. Ул үз хыялын тормышка ашыра. Халык җилкәсендә яшәп, аштан-ашка йөрүче муллага әверелә.

**«Назлы кияү».** Автор төп герой Рәшитнең мәгънәсез эш-һөнәрен ирония белән көтсә дә пьесадагы вакыйгалар гаилә, көнкүреш кысаларыннан чыкмый. Әсәрдә Рәшит исемле «назлы кияү» ерак Төркестаннан Казанга өйләнергә дип килә. Күпме эзләсәдә кыз табалмагач, асравы Гайнигә өйләнеп, кайтып хур була.

**«Соңгы сәлам» (1917**) драмасында шәхес фаҗигасе тасвирлана. Әсәрдә төп конфликт көчле мәхәббәт һәм аның милли мохит бәрелешендә сәүдәгәр бай Вахит миллионер Вахрушевның кызын ошата. Ул гаиләсен ташларга, татарлыгын онытырга тиеш була. Вахитның көчле мәхәббәт тозагында бәргәләнүе, соң чиктә үлемгә алып килә. Аның үлемендә 2 милләт мохите аермасы төп сәбәпче. Вахит Мансуров тормыш мохитында адашып калган шәхес.

Кәрим Тинчурин Октярь революциясен ихлас күңелдән каршы ала. Аңа чын күңелдән ышана. 1919 елда «Эш» газетасында басылган бер мәкаләсендә: «Татар театрының хәзерге дәвере эшчеләр өчен иң күңеле дәвердер» - дип яза.

Яңача җәмгыять төзү юлында «Сакла шартламасын» (1918), «Зар» (1923), «Казан сөлгесе» (1923), «Американ»(1924), !Җилкәнсезләр» (1925) комедия һәм драмаларын иҗат итә.

20 нче еллар урталарында Кәрим Тинчурин музыкаль драмалар язуга да игътибарын юнәлтә. Аның чакыруы буенча Оренбургтан татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы Салих Сәйдәшев кайта һәм аларның шунда дуслыклары башлана. Уртак иҗатлары нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл», «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930) кебек татар сәнгатенең алтын фондын тәшкил иткән әсәрләр туа. 30 елларда ул совет чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Алар өчәү иде» пьесаларын иҗат итә. 20 нче еллар драматургиясендәге ачышы: Кәрим Тинчуринга кадәр сәхнәдә күмәк күренешләргә, опера һәм балет элементларына, халык эстетикасына, милли харктерларга бик аз урын бирелә. Аларны Кәрим Тинчурин алып керә.

«**Җилкәнсезләр**» (1926) сатирик комедия милли фаҗигане чагылдырган җитди әсәр. Әсәрдә вакыт чикләре 1910-1923-24 елларны эченә ала. 20-ләп

образ бирелгән, үзәктә Нуретдин бай гаиләсе. Рокыя, Дилбәр, Давыт – аның балалары. Комедия 8 картинадан тора, 8 картина буена Насих кебек хаҗилар, аларның ялчысы Батырханнар, комсыз сәүдәгәрләр дөбер-шатыр килеп тарих баскычыннан төшә баралар һәм ахырда идән астына посалар. Биредә алар «Җилкәнсез» кешеләр кебек биреләләр. Әсәргә бүгенге күзлектән карасаң, монда геройларның һәркайсы да чилкәнсез. Уңай геройлар Сөнгать белән Рокыяда, сатирик геройлар Батырхан, Нуретдин, Насих, Давыт, Дилбәр дә халыкның күнегелгән яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен бетереп, телдән, диннән аерырга тырышу бик күпләрне бәхетсез, җилкәнсез итә. Автор – ул тискәре персонажларны беркайчанда әсәр башыннан ук мескен, мыскыллы, көлкеле итеп сурәтләми, алар әсәр барышында гына сүзләре уй-гамәлләре аша ачылалар.

**«Сүнгән йолдызлар»**. Әсәр беренче Бөтендөнья сугышы вакыйгаларын үз эченә ала. Ил өстенә якты йолдыз булып кабынган яшьләрнең вакытсыз сүнүен бөтен ил драмасы белән кушып бирә. Әсәрдә сугыш афәтенең чагышылы яктыртыла.

Әллә кемнәр файдасы өчен генә балалар сугыш кырларында газап чигәләр… Кемгә кирәк соң бу сугыш, кемгә кирәк? - дигән юллар әсәрне эмоциональ киеренке кайнар сулышлы сәнгать әсәре булып китүгә, күңелгә кереп калуга сәбәпче. Драмада киеренкелекне мәхәббәт өчпочмагы да арттыра. Исмәгыйль белән Сәрвәр илаһи сөюләр белән яраталар. Әмма Сәрвәрне гарип Надирда ярата. Надир Исмәгыйль хезмәт күрсәтә торган хәзрәтнең улы, тиздән мулла булырга җыена, бай кеше.

Сәрвәр Исмәгыйль кабере янында үлә. Моны күргән Надир «хуш, хуш күгәрченем, хуш бердәнбер куанычым, ходай синең җаныңны алып, актык йолдызымны сүндерде… Сукырның актык таягын сындырды» - дип чынбарлыкка протестын үлем белән белдерә, һәм «Мин үземә үзем хуҗа!» дип үзен-үзе үтерә.

Кешеләрнең бәхете киселүгә, гомере өзелүгә, халыкка фаҗига килүгә сәбәп – сугыш, дигән фикер пьесаны үтәли чыга.

Халык эстетикасы нигезендә бирелгән Канат образы, ирекле очыш, хөр яшәү, табигый теләк-хыяллар символы буларак, пьесада тирән мәгънәле һәм эзлекле кулланыла. «Канат сатам» уены кабатлану, «Каз канаты» җыры яңгырау, «ир канаты» образы ассызыклану – барысы да әлеге мотивка бәйләнешле.

Автор табышы – Надир образы. Ул чын мәгънәсендә татарның гарип, шыксыз, куркыныч кыяфәтле кешегә Кәрим Тинчурин кеше-психолог буларак якын килә. Әйе, Надир да бит кеше. Аның да бит аз гына булса да бәхетле булырга хакы бар. Тик аның җанын, йөрәген аңлаучы юк. Аның Сәрвәрне мәҗбүр итәсе килми. Сәрвәр аны кызгана гына, яратмый.

К. Тинчуринга кадәр мондый көчле психологик кичерешләргә ия булган образ иҗат итүче, татар драматургиясендә әле булмый. Бу - аның табышы, зур яңалыгы.

«**Зәңгәр шәл**» - халык драмасы, мелодрама. Үзәк героиня Мәйсәрә ятимә кыз. Үз бәхете өчен көрәшергә әзер шәхес буларак күзаллана. Сөйгәне ил, җир күргән батыр егет - Булат. Үзәктә - яшьлек, мәхәббәт, өмет һәм омтылышлар. Әсәр Булат белән Мәйсәрәнең тантаналы мәхәббәте белән тәмамлана. Качкыннар турында сюжетлар да бирелә. Сатирик типлар: ишан, 4 хатыны.

Әсәр Салих Сәйдәшевнең җырлары белән бизәлгән лирик сюжет, халык йолалары, уен- биюләрне мул куллану, әсәрне озын гомерле иткән.

«**Американ**» – җыйнак, 4 пәрдәле комедия. Әсәрдә яңа җәмгыятьне кабул итә алмаган Муса, Габдуллаҗан кебек кешеләрнең чын йөзе бер төркем студентлар тарафыннан ачыла. Үзләрен милләт өчен янып йөрүчеләр дип санаган бу кешеләрнең хыялы – монда акча туплап Америкага качу.

«**Ил**» - мелодрама. Этнографик һәм фольклорчыл әсәр, милли аң уянуын шәхес азатлыгы темасын үзәккә куя.

Прозаик буларак ул революциягә кадәр танылa. 1914-1917 елларда «Аң» журналында, «Кояш» газеталарында хикәяләре басыла.

«**Мәрҗәннәр**» - әлеге хикәяләр тезмәсен автор үзе новеллалар дип атый. Әсар автобиографик характерда мин исеменнән сөйләнмәсә дә төп герой

Сөләйман исемле шәкертнең прототибы – Кәрим Тинчурин үзе була. Әсәр 1935-37 елларда язылса да, бары тик 70 нче елда гына Казанда китап буларак басылып чыга.

К.Тинчуринның комедия остасы буларак танылуы. Октябрь инкыйлабыннан соң татар профессиональ театрын үстерүдәге өлеше. “Американ”, “Җилкәнсезләр”, “Хикмәтле доклад” комедияләре.

“Зәңгәр шәл”, “Казан сөлгесе”, “Кандыр буе”, “Ил” музыкаль драмалары, аларның проблематикасы, сәнгатьчә эшләнеше. Иҗатына вульгар социологизмның тәэсире.

## УТЫЗЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ. ӘДӘБИ ХӘРӘКӘТ. ПРОЗА. ДРАМАТУРГИЯ, ПОЭЗИЯ.

Кеше хокукларын бозып, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү сәясәте. Моның татар халкын тагын да таратуга, аеруча эшлекле, икътисади, мәдәни, дини тормышның нигезен тәшкил иткән өлешен юкка чыгаруга китерүе.

Мәгариф, мәдәният, фән, әдәбият-сәнгатьнең ул еллардагы торышына күзәтү. Илдә демократиянең әкренләп юкка чыгарылуы, кеше хокукларының тупас бозылуы. Җинаятьчел бер төркемнең җитәкчелекне үз кулында туплавы, пролетариат диктатурасы исеме астында шәхси хакимият урнаштырып, илне яңадан халыклар төрмәсенә әверелдерүләре. Азчылык милләтләрнең телләрен чикләү, язуларын алыштыру, аларны эрерәк милләтләр эчендә аралаштырып бетерү сәясәте уздырылу. 1940 елның I январеннан төрки телле халыкларның, шул исәптән татар халкының латин графикасына нигезләнгән язуларын кириллица хәрефләре ярдәмендә төзелгән алфавитка көчләп күчерү. Моның әдәби,мәдәни, мәгариф эшенә китергән зур зыяны.

Язучыларны бер оешмага – СССР Язучылар берлегенә туплау. Татарстан һәм СССР язучыларының беренче съездлары. Аларда кабул ителгән карарлар. Әдәбиятның төп иҗат методы итеп социалистик реализм методының раслануы. Моның әдәби иҗатка тискәре нәтиҗәләр китерүе. Коммунистик фиркалекле

принцибының асылы. Сыйнфый мәнафәгатьләрнең үзәктә торырга тиешлеге. Яңа тормышның искесенә каршы куелуы, беренчесенең өстенлеге расланунының мәҗбүрилеге. Юлбашчыларны данлауның әдәбият-сәнгатьтә иң алгы планга чыгуы. Тәнкыйтьтә вульгар социологизмның ныгып урнашуы. Милли әдәбият традицияләренә таянуның йомшаруы. Иҗат ирегенең нык чикләнүе, моның әдәби әсәрләрне төссезләндерүгә китерүе. Күренекле язучыларның шәхес культы корбаны булуы: Г. Ибраһимов, К.Тинчурин, Ф. Бурнаш, М. Галәү, Ш. Усманов, Ф.С. Казанлы, Г. Нигъмәти, С.Сүнчәләй, Г. Толымбайский, Г.Гали һ.б. Ф. Кәрим, Х. Туфан, И. Салахов, К. Нәҗми, С. Әдһәмова, М. Рафиков, Г. Хәсәнов, М. Шабай һ.б.ларның кулга алынып, төрмәләрдә, сөргеннәрдә тотылулары. Төрмәләрдә иҗат ителгән әсәрләр.

Әдәбиятта күтәрелгән темалар хәлле, таза тормышлы, эшчән кешеләрен) бетерү, илне индустрияләштерү, капитализм һөҗүменнән саклану, дингә каршы көрәш, яшьләрнең яңа тормыш төзү өчен көрәш алып баруларын сурәтләүнең катгый таләп итеп куелуы. Фәкать уңай геройның социализм өчен көрәшченең өстенлек алуын күрсәтүнең мәҗбүрилеге. Хосусый милекчелекне фаш итү, күмәклек психологиясенең тормышчанлыгын раслауга тоткан юнәлеш.

Бу чорның аеруча күренекле һәм үзенчәлекле шагыйрьләре: Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, С. Баттал һ.б. Поэма жанрының активлашуы. Аеруча киң танылган поэмалар. Х.Туфанның «Ант» поэмасы тирәсендә барган идеологик көрәш. Либреттолар иҗат итүнең җанлануы.

Бу еллар прозасының йөзен билгеләүче әсәрләр: «Безнең көннәр» (Г. Ибраһимов), «Матур туганда» (Ш. Камал), «Канлы тамгалар» (М. Галәү), «Агыйдел», «Безнең авыл кешесе» (М. Әмир), «Бригадир кыз», «Көмеш сулы Нурминкә» (И. Гази), «тапшырылмаган хатлар» (Г. Кутуй), «Сиваш» (Г. Бәширов), «Чын мәхәббәт» (Л.Гыйльми), «түбән елгада» (Г. Толымбай), «Кояшлы яңгыр» (К. Нәҗми), «Бер мәхәббәт турында», «Госпитальдә», «Ана», «Туйда» (А.Шамов), «Гармунчы» (Ф.Хөсни), «Горизонт» (Р. Ильяс) һ.б. Аларның күпчелегендә сыйнфый көрәшнең үзәктә торуы, чорның драматизмы чагылуы. Прозада өслүп төрлелеге.

Әдәби тәнкыйтьтә тел-стиль турындагы бәхәсләр.

Иҗат эшлекләләрен эзәрлекләүнең башлануы. «Җидегән» исемле язучылар төркеме дигән нә»рсә уйлап чыгару, шуны файдаланып, каләм әһелләренә каршы көрәш оештыру. Әдәби үсешкә зур зыян килү. Мәдәни мираска тискәре мөнәсәбәт. Әдәби осталыкка булган таләпнең кимүе.

Драматургиядә еш кына конфликтның ясалмалылыгы. Шундый әсәрләрдән: «Таулар» (Ш. Камал), «Җавап» (Г. Кутуй), «Дәүләт Бәдриев» (Г.Иделле), «Гудок» (Х. Җәмил), «Мактаулы заман» (Т. Гыйззәт) һ.б.

Ватанпәрвәрлек мәүзәгы яктыртылган әсәрләр: «Идегәй» (Н.Исәнбәт), «Таймасовлар» (Т.Гыйззәт), «Ил өчен» (Р. Ишморат), «Ил чигендә» (Г. Насрый).

Халык тормышының фаҗигале үткәннәренә багышланган «Миркәй белән Айсылу» (Н. Исәнбәт), «Шәмсекамәр» ( М.Әблиев) әсәрләре.

Фольклорга нигезләнгән сәхнә әсәрләренең иҗат ителүе: «Хуҗа Насретдин» (Н .Исәнбәт), «Кыю кызлар» ( Т.Гыйззәт).

Тарихи шәхесләргә багышланган драма әсәрләре: «Пугачев Казанда», «Тукай» (Ә. Фәйзи), «Спартак», «Идегәй» ( Н. Исәнбәт).

Татар дәүләт академия театрында уңыш белән барган әсәрләр: «Ватан», «Гөлзада»» (Р. Ишморат), «Урманда» (Ф. Хөсни), «Сынау» (С. Баттал), «Күзләр» (Х. Фатхуллин), «Гөлчәчәк» (Г. Минский) һ.б. Югарыда исемнәре аталган әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре, аларның шул еллар эстетик таләпләреннән азат булмаулары.

Балалар әдәбияты. Бу өлкәдә Ф. Кәрим, А. Әхмәт, Ш. Гәрәй, Д. Аппакова һ.б. әсәрләре.

Вакытлы матбугатта әдәбият-сәнгать турында барган бәхәсләр.

## Ш.КАМАЛ, Ф.БУРНАШ, Г.КУТУЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КОНФЛИКТ ЯҢАЛЫГЫ.

**Шәриф Камал (1884-1942).** Язучының инкыйлабка кадәрге иҗатына кыскача күзәтү. Тормышы. Әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге. «Таң атканда» романы. Әсәрдә төрле социаль катлауларның инкыйлабка мөнәсәбәтен сурәтләү. Романда сәнгатьчә яңалыклар, анда реализм белән сатираның табигый үрелүе.

Әдипнең Оренбургтан Казанга кайтуы, моның сәбәбе.

Ш.Камалның инкыйлабтан соңгы тормышны эстетик өйрәнергә омтылуы нәтиҗәсе буларак «Матур туганда» романы. Язучының матурлык төшенчәсен сыйнфый карашлар яктылыгында аңлавы. Образлар системасы, кеше характерларын тудыруда язучы кулланган сәнгать чаралары. Инкыйлаб һәм кеше язмышы мәсьәләсе. Сыйнфый көрәшнең үзәккә куелуы. Композиция һәм стиль үзенчәлеге. Ш.Камал прозасының үзенә генә хас яклары.

Ш. Камал – драматург. Сәхнә әсәрләренең проблематикасы. Кеше язмышларын күрсәтүдә сыйнфыйлык принцибының өстенлек итүе. Конфликтларның оешу үзенчәлекләре. Язучының психологик осталыгы. «Козгыннар оясында», «Габбас Галин», «Таулар», «Ут» драмаларына анализ.

Әдипнең публицистикасы. «Без җиңәрбез», «Дошман бетерелергә тиеш» исемле мәкаләләре. Тәрҗемә өлкәсендә эшчәнлеге. Әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре, аларда үткәрелгән карашлары.

Ш.Камалның "Матур туганда" романы. Әдипнең матурлык төшенчәсен сыйнфыйлык аша аңларга омтылышы. "Акчарлаклар"ның дәвамы буларак "Таң атканда" романы. Рәсми идеология тәэсире нәтиҗәсендә әсәрнең "йомшак" булуы. Сәхнә әсәрләренең проблематикасы.

**Фәтхи Бурнаш (1898-1942).** Ф.Бурнаш – шагыйрь һәм драматург. Тормыш юлы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге. Иҗатындагы романтик рух. Поэма жанрын үстерүдәге эшчәнлеге. Аларның тематикасында һәм сәнгатьчә

эшләнешендәге үзенчәлекләр. «Чәчәктән һәйкәл», «Гөлчәчәк», «Сахра каны», «Ак каен», «Әҗәл» поэмалары. Шигырьләре.

Ф.Бурнашның вакытлы матбугатны оештырудагы эшчәнлеге. «Көн» («Таң»), «Кызыл Армия», «Татарстан» газеталарында мөхәррирлек итүе. «Безнең юл», «Чаян» журналларын нигезләүдә катнашуы.

«Таһир-Зөһрә» трагедиясе һәм «Яшь йөрәкләр» драмасының Ф.Бурнашны талантлы драматург итеп танытуы. «Шәмсия» романтик драмасында инкыйлаби аскетизм идеясен үткәрүе. Халыкның фаҗигале язмышын күрсәтү ягыннан «Хөсәен мирза» драмасы. «Оҗмах кошы» әсәренең проблематикасы, әсәрнең кискен тәнкыйтькә очравының сәбәпләре. «Камали карт», «Ялгыз Ярулла» комедияләренең җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә бәйле рәвештә кеше язмышының драмасын ачулары. Типлар сурәтләнеше «Адашкан кыз», «Лачыннар», «Таң», «Тукучы Әсма», «Олы юл буйлап» пьесалары. Җәмгыятьнең төрле катламнарындагы тормышны эстетик үзләштерүгә омтылыш, бу юлдагы уңышлыклар һәм кыенлыклар.

Ф.Бурнашның шигъриятtә сатирик юнәлешне үстерүгә керткән өлеше. Мондый әсәрләрнең тематикасы, проблематикасы, кулланылган сәнгатьчә алымнар. Опера либреттолары иҗат итү, тәрҗемә, публицистика, әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәләрендәге эшчәнлеге.

Талантлы шагыйрь һәм драматургның фаҗигале язмышы турындагы мәкаләләр. Ф.Бурнаш иҗаты турында күренекле шәхесләрнең фикерләре.

**Гадел Кутуй (1903-1945).** Язучының тормыш юлы һәм иҗаты. Әдәби сәләтенең рус әдипләре А. Неверов, В. Маяковский тәэсире белән ачылып китүе. Футурист шагыйрь буларак танылуы. 1924 елда «Көннәр йөгергәндә» исемле беренче җыентыгы дөнья күрү. 30 елларда прозаик һәм драматург буларак та танылу.

«Балдызкай», «Җавап», «Солтанның бер көне», «Вөҗдан газабы» «Илһам» әсәрләрендә чорның әхлакый-эстетик мәсьәләләренең куелышы.

«Тапшырылмаган хатлар» повестенең басылуы. Галия образының үзенчәлеге.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) 30 нчы елларда драматургия (Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Таҗи Гыйззәт).

2) 30 нчы елларда социалистик реализм методының урнашуы.

3) Шәриф Камал әсәрләрендә чор тенденцияләре. («Таң атканда», «Матур туганда»).

4) Гадел Кутуй. Башлангыч чор иҗаты. «Тапшырылмаган хатлар», «Күк күгәрчен», «Шатлык җыры»).

5) Кәрим Тинчурин. Башлангыч чор иҗаты. «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе». «Американ».

6) Фәтхи Бурнаш иҗаты. «Таһир Зөһрә», «Яшь йөрәкләр», «Чәчәктән һәйкәл», «Ак каен», «Хөсәен Мирза», «Камали карт», «Олы юл белән».

**Гамәли биремнәр:**

1. Шәриф Камалның тормышы һәм иҗатына кыскача күзәтү. XX йөз башы иҗатына кыскача күзәтү.
2. Әдәби иҗтимагый эшчәнлеге. Әдипнең Оренбургтан Казанга кайтуы, моның сәбәбе.
1. 20 нче еллар иҗаты. Зур күләмле әсәре – «Таң атканда» романы. «Акчарлаклар»ның дәвамы буларак, әсәрдә төрле социаль катлауларның инкыйлабка мөнәсәбәтен сурәтләү.
2. «Козгыннар оясында», «Ут», «Габбас Галин», «Таулар». Әсәрләрдә сурәтләнгән төп вакыйгалар һәм аларны тирән ачуга буйсындырылган факторлар.
3. 30 нчы еллар ахырындагы иҗаты. «Матур туганда» романы, әсәрнең сюжет-композицсяе, тел үзенчәлекләре.
4. «Матур туганда» әсәренең дәвамы булган «Ныклы адымнар» (тәмамланмаган). һ.б. әсәрләренә анализ.

**Глоссарий:**. Контраст – кеше характерының, предметның, күренешнең үзенчәлекләрен, сыйфатларын икенчесенә капма-каршы кую.

**Әдәбият:**

1. Җәләлиева М.Ш. Тарих әһеле // Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. – Казан: «Мәгариф», – 42-47 б.

2. Закирҗанов Ә. М. «Беренче адымнар» // Заман белән бергә. – Казан, 2007. – 139-145 б.

## ТЕМА № 4

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ (1895-1955) – РЕВОЛЮЦИОНЕР, РОМАНИСТ, ДРАМАТУРГ. КАВИ НӘҖМИ (1901-1957) ИҖАТЫ.

**Аннотация**: Таҗи Гыйззәт үзенең иҗатын яңа шартларда – Октябрь революциясеннән соң яңа совет идеологиясе йогынтысы көчәйгән чорда башлап җибәрә. Күп кенә пьессаларында шушы идеяләрнең көндәлек уй-фикерләрен, аларның хыялларын чагылдыра.

Кави Нәҗми – Совет чоры татар әдәбиятының күренекле вәкиле – прозаик. шагыйрь, тәнкыйтьче-публимцист һәм җәмәгать эшлеклесе. казандагы әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган, поэзия жанрында да, проза жанрында да, күп яза, публицистика, аби тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшли. Әсәрләрендә яңа тормыш төзү идеологиясе һәм пафосы хөкем сөрә, Гражданнар сугышы, авылдагы сыйнфый көрәш вакыйгалары чагыла.

**Мөһим сүзләр**: авыл тормышы, сыйнфый көрәш, революция үзгәрешләре.

**Таҗи Гыйззәт (1895-1955).** Тулы исеме Таҗетдин Кәлимулла улы Гыйззәт 1895 елның 3 (яңа стиль буенча 15) сентябрендә Алабуга өязе Баржы Умга авылында ярлы балта остасы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә 5 малай була. Әтисенең фаҗигале тормышы күңелендә тирән эз

калдыра. 1900 елда урман кисүдә гаепләнеп Кәлимулла абый 2 ел төрмәдә утыра.

1906 елда яңадан кулга алына. Монысының сәбәбен Таҗи Гыйззәт язып калдырмый, 7 ел үткәч, ягъни 1913 елда Романовлар династиясенең 300 еллык юбилее уңаеннан әтисе амнистиягә эләгеп азат ителә. Әмма сәламәтлеге нык какшау аркасында 3 айдан соң ашказаны авыруыннан вафат була. Шуңа күрә ата кеше, ир кеше эшли торган эшләрнең күбесе әнисе һәм Таҗетдин җилкәсенә төшә.

1903 елда остазбикәгә йөри башлый. Аннары авылда яңа мәчет ачылгач, шунда укый. Ижбуби мәдрәсәсе мөгаллимнәреннән дә белем ала. Әмма 1911 елда ачлык аркасында укуын ташларга мәҗбүр була.

1913 елда гына Ижау заводына эшкә керә. Иң актив яшьләрдән санала. Гражданнар сугышы башлангач Кызыл армия сафларында хезмәт итә. Монда да ул үзешчән спектакльләр куеп йөри.

1922 елда Казанга кайта. Татар дәүләт театрына артист булып урнаша. 1923 елда Сембер шәһәренә китә, һәм андагы театр труппасы белән җитәкчелек итә. Режиссер һәм артист булуы өстеннән үзе дә пьесалар яза. Төрле җирләрдә булуы, төрле кешеләр белән аралашуы, пьесалары өчен бай материал тупларга ярдәм итә.

1939 елда РСФРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелә.

**Таҗи Гыйззәт драматургиясе**.

Беренче пьесаларында ук игътибар үзәгенә инкыйлабка кадәрге крестьян тормышы алына.

1861 елның, 1917 елга кадәрге гади халыкларның авыр тормышы, аның берничә әсәрләрендә сурәтләнә.

«**Наемщик**» (бер кешенең икенче кеше өчен солдат хезмәтенә алынуы). Әсәрдә Батырҗан бай малае Тимерхан өчен солдатка алынырга тиеш була. Әсәр башта комедия жанры буларак уйнатыла (1926-27 елларда). Әмма соңрак, 30 елларга таба Таҗи Гыйззәт Алабугада торганда әсәрнең яңа вариантын төзи һәм музыкаль тарихи драмага әйләнә. Пьеса Алабуга, Чаллы, Бондюк

шәһәрләрендә сәхнәләштерелә. Төп рольләрне уйнаучылардан Ильяс Ашхазарский, Зәйни Солтан, Айдаров һ.б. артистларны атап була.

Әсәр башында без 1861 елда крестьянның тормышы белән танышабыз. Йөзкәй түрәләр, Иманкол муллалар, Байбурин кебек алпавытлар, Шәрифә абыстай кебек морза хатыннары, управляющий Бикташ, ятим балаларга , эшли алмаган карт һәм карчыкларга бер кисәк тә ипи бирелми. Крестьяннарның кырларына куяннарны кудырып ашлыкны таптаталар. Сөйгән ярларны бер-берсеннән аерып дусларына ничәнчедер хатынлыкка бүләк итәләр һәм барлык бу явызлыкккa каршы Батырҗан баш күтәрә һәм ул ялгызы гына түгел. Геройларның үзара сөйләшүләреннән икенче авылларда да алпавытларның имениеләрен яндырылганлыкны беләбез. Морзаларга һөҗүм ясаганнан соң Батырҗан урманга кача. Әмма качкыннар арасында яшәү аны канәгатьләндерми. Соңгы тапкыр туганнары белән күрешеп Урал якларына китәргә була. Батырҗанның авылга килүе беленә, ул үзе дә тик утырмый, крестьяннарга аңлату эшләре алып бара, чөнки Александр патша крестьяннарга ирек бирү турында манефест чыгарса да җир барыбер байлар кулында кала.

30 нчы елларда Таҗи Гыйззәт аеруча актив иҗат итә. Әмма ул чорда язылган әсәрләрнең барысын да диярлек агиткалар дип атап була. Шул елларда язылган әсәрләреннән түбәндәгеләрне атарга мөмкин: «Бөек борылыш» (1930), «Көрәш» (1931), «Акбаш вакыйгасы» (1932), «Ударник Мохтар» (1932), «Җиңү бәйрәме» (1933), «Фамилиясез тимерче» (1933) щундыйлардан. Шулай ук колхозлашу чорын чагылдыруга «Мактаулы заман» (1935) пьесасын багышланган. Бу елларда «Бишбүләк» (1932), «Чаткылар» (1934), «Кыю кызлар» (1939) пьесаларын яза.

«Изге аманәт» (1944), «Чын мәхәббәт», «Алсу таң» (1954), «Үрнәк адымнар» (1953) һ.б. әсәрләре белән халык күңелен яулады.

1955 елның мартында вафат булды.

**Кави Нәҗми иҗаты (1901-1957).** Әдәбиятка килү юлы. Бу гаиләнең язмышында, гомумән, татар халкына хас хәл-әхвәлнең чагылыш табуы. К. Нәҗминең 1917 елдан соңгы вакыйгаларга мөнәсәбәте, иҗатында чагылдыруы.

Яшь каләм әһеленең идея-эстетик эзләнүләре. Әдәби мираска, сүз сәнгатендә тупланган мәгълүм тәҗрибәгә мөнәсәбәте. Шигърияттә имажинизмны хуплавы, бу хактагы карашлары чагылдырылган язмалары. Шагыйрь буларак, иҗади юнәлеш–ләрендәге хәрәкәтне күзәтү.

Шигъриятттәге иҗади эзләнүләренең чәчмә әсәрләрендә чагылышы. Бу яктан «Шобага» хикәясенең язылу тарихы. Чынбарлыкны табигый сурәтләү юнәлешенең өстенлек алуы. «Яр буендагы учаклар» әсәрендә язучы каләменең үзенчәлекле яклары ачылу. Кеше образларын тудырудагы сәнгатьчә чаралар. К. Нәҗми һәм М. Горький.

Сыйнфый көрәшне тасвирлауның К. Нәҗми иҗатында төп тема булып әверелүе. «Кояшлы яңгыр», «Якты сукмак» әсәрләрендә чынбарлыкның сурәтләнеше, образлар тудыруда язучы кулланган алымнар. Бу әсәрләренең танып-белү әһәмияте.

Татарстанда утызынчы еллар әдәбият тормышында К. Нәҗминең эшчәнлеге. Татар әдәбиятын ил күләмендә таныту юнәлешендә ул керткән өлеш. Ватан сугышы елларындагы иҗаты.

«Язгы җилләр» тарихи-инкыйлабый романының, язылу тарихы. Әсәрнең темасы, язучы әйтергә теләгән төп фикер. Романда тормыш дөреслеге белән сәнгатьчә дөреслек арасындагы мөнәсәбәт. Образларның гомуми һәм индивидуаль сыйфатлары. Төзелешендәге үзенчәлекле яклар, сәнгатьчә эшләнешендәге кимчелекләр.

Авторның мәгълүм идеологик таләпләр тәэсирендә булуы, моның «Язгы җилләр» романында чагылыш табуы. Әсәргә ул елларга бирелгән бәя. Язучының алга таба әсәрнең дәвамын язу өстендәге эше. Бүгенге әдәбият белемендә һәм тәнкыйтендә «Язгы җилләр» романы хакындагы каршылыклы фикерләр.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Т.Гыйззәтнең “Ташкыннар” трилогиясе. Өлешләрнең аерым һәм трилогиянең тулаем проблематикасы.

2) К.Нәҗминең “Кояшлы яңгыр”, “Якты сукмак” әсәрләрендә чынбарлыкның берьяклы сурәтләүе.

**Гамәли биремнәр:**

1. Т.Гыйззәт иҗатының үсеш этаплары. Пьесаларында инкыйлабка кадәрге татар авылы тормышының бирелеше, татар крестьяннары хәлен тарихи дәвамлылыкта күрсәтү. “Ташкыннар” трилогиясендә Биктимер һәм Аюхановлар гаиләсе аша сыйнфый каршылыкны күрсәтү.

2. Кави Нәҗминең ортадоксаль пролетариат әдәбияты тарафдары булып формалашуы. “Кояшлы яңгыр”, “Якты сукмак”, “Яр буенда учаклар” повестьларында чынбарлыкның берьяклы сурәтләнеше.

**Глоссарий**: драма - матур әдәбиятның бер төре; тормышчан конфликтка, вакыйгаларны геройларның эш һәм хәрәкәтләре аша ачуга корылган диалог һәм монолог формасында язылган сәхнә әсәрләре. хәзер күбрәг драматургия термины белән белдерелә.

**Әдәбият** :

1. Татар әдәбияты тарихы – 6 томда, Т.4. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989.

**2.** Даутов Р. Әдипнең фаҗигасе//Казан утлары –1996. – № 9.

## ТЕМА № 5
## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ.

**Аннотация**: Публицистиканың башка жанрларга тәэсире. Сугыш вакыйгаларына бәйле рәвештә шигъриятнең үзгәреше. Гади совет солдатын, аның эчке кичерешләрен алгы планга куеп сурәтләү.

**Мөһим сүзләр.** Сугыш чоры, тыл, контраст сыйфатлар, яшәү һәм үлем, батырлык..

Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты аеруча үзенчәлекле, чөнки ул сугыш барган вакыт белән тәңгәл килә – 5 ел эчендә формалаша, иҗат ителә. Биш елны мөстәкыйль чор дип атап булган бердән бер очрак бу.

Әйтергә кирәк, сугыш чоры әдәбияты (1941-1945 еллар) һәм сугыш турындагы әдәбият (сугыштан соң иҗат ителгән әсәрләр), тема бер үк кебек күренсә дә, чынлыкта, төрле чор әдәбиятлары, димәк, куйган проблемалары, нәтиҗәдә – фикерләре дә төрле.

Сугыш чорларында татар шагыйрьләре, прозаиклары, драматурглары иҗат иткән күренекле әсәрләр XX йөз татар әдәбиятының алтын фондына керә. Алар: М. Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре”, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, С. Хәким, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррисләрнең лирикасы, Ф. Хөснинең “Йөзек кашы” (1942), Ф. Кәримнең “Разведчик язмалары” (1943), И. Газинең “Алар өчәү иде” (1944) повестьлары, Ә. Еникинең “Бер генә сәгатькә” (1944) хикәясе, М. Әмирнең “Миңлекамал” (1944), Р. Ишморатның “Кайту” (1942) пьесалары һ. б.

Әсәрләрдә конфликтның капма-каршы куелган контраст сыйфатлар, күренешләр, карашлар белән бәйле булуы бу чор әдәбиятының үзенчәлеге булывп тора. Яшәү һәм үлем, ирек һәм коллык, батырлык һәм куркаклык, фидакярлек һәм хыянәть төшенчәләре арасына кеше җаны, рухы куелды. Гомумән, сугыш кеше характерында гадәти хәлләрдә күпмедер килешеп, “тынып” яши торган сыйфатларны ике чиккә аерып куйды, көчәйтте. Гадәттән тыш шартларда башкача була да алмый иде.

Әдәбиятка шул чорның герое – совет кешесе, совет солдаты образы килде. Ул – бик күп әсәрләр өчен уртак образ, бер үк сыйфатларга, иң кирәкле сыйфатларга ия булган кеше. Шул ук вакытта аңа капма-каршы куелган дошман образы җанлы кеше буларак тасвирланмады да, аңа “дошман”, “илбасар”, “ерткыч”, “фашист” исемнәре генә бирелде. Алар кешелекнең дошманы буларак кабул ителде, бары ерткычлык сыйфатлары гына гәүдәләнде.

Сугыш елларындагы әсәрләр еш кына ут эчендә, һич югы окоп шартларында, землянкадагы сукыр лампа яктысында, редакция машинасында языла. Фронт газеталарында кайсы мөхәррир, кайсы хәрби хәбәрче буларак М. Җәлил, Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Р. Ишморат, И. Гази, Г. Галиев, Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, Ә.Ерикәй, Г. Насрый, М. Садри, Г. Хуҗи, Г. Әпсәләмов, һ. б. эшли.

Мәскәүдә яшәп, 1940 елда әдәбият институтын тәмамлаган яшь язучы Г. Әпсәләмов өчен сугыш дөньяны танып-белү, чыныгу мәктәбенә әйләнә. Карелиядә, сугыш шартларында, ул бер-бер артлы матур гына хикәяләр яза башлый. Аның тормышчан язмалары әледән-әле "Совет әдәбияты" журналы битләрендә күренә, 1944 елда исә "Төньяк балкышы" исеме белән җыентык булып чыга. Хикәяләрнең геройлары арасында уртаклык зур, алар үзенең гаиләсен, илен якларга ант иткән кешеләр, җиңүгә ышанып аларны әллә ничә үлемнән саклап кала. Туган илнең зурлыгы, төрле милләт халыкларының туганнарча дуслыгы аларны рухландырып тора, хис-кичерешләре дә бер үк.

Ф. Кәримнең "Разведчик язмалары", И. Газинең "Алар өчәү иде" повестьларында сугыштагы иң гаярь егетләрнең-разведчикларның эшчәнлеге тасвирлана. Разведчикларга икеләтә кыен: алар дошманның башбаштаклыгын күреп торган хәлдә дә, җәбер-золым кичерүчеләргә ярдәм итә алмыйлар. Бу хәл алардагы нәфрәт хисен арттыра, үч алырга чакыра.

И. Газинең "Кышкы кичтә", "Әхмәт бабай" хикәяләрендә дошман кулы астында яшәүнең кешене ни кадәр түбәнсетүе тасвирлана. Фашизм, гомумән дә, кешелек сыйфатларыннан мәхрүм, аңа бары тик ерткычлык кына хас, дигән фикер үткәрелә.

Тылдагы тормыш турындагы әсәрләр сугыш чоры әдәбиятының аерым бер төркемен тәшкил итә. Һәркем белә, алдагы тормышны сугышның язмышы хәл итәчәк. Әсәрләрдә бу фикер ачык үткәрелә.

Ф. Хөсни "Түбән оч" хикәясендә әһәмиятле мәсьәләне калкытып куя: сугыш чоры законнары, беренче карашка кешелеклелек сыйфатларына каршы килсә дә, гадәттән тыш әһәмиятле, хәлиткеч ситуация-хәлләрдә кешеләр шул

чор законнары буенча көн итәләр, гомуми таләпкә һәркем буйсынып яшәргә тиеш. Бүтәнчә булган очракта максатка барып җитеп булмаячак, таркаулык килеп чыгачак.

А. Шамовның “Буранлы төндә” хикәясе дә шул ук законнар турында, ситуация-вакыйга гына башка.

Теләсә нинди авыр шартларда да кеше күңеле ниндидер яктылык эзли. М. Әмирнең “Мөстәкыйм карт йокысы” дигән хикәясе шуның ачык мисалы. Искиткеч якты, матур һәм шаян җыр кебек бу хикәя. Йокларга яратучы Мөстәкыйм картны һич кенә дә ялкау дип әйтеп булмый. Тугызынчы унны куса да сугыш вакытында ул колхоз эшенә үзе теләп алына, хатын-кызлар эшли алмаган кул эшләрен бер үзе алып бара. Ләкин холык-фигыленең мөлаем бер үзенчәлеге – иң кирәксез вакытларда изрәп йокыга китүе шактый мәзәк хәлләргә очравын сәбәпче була.

Татар әдәбиятына ялкынлы шагыйрь булып килеп кергән һәм “Тапшырылмаган хатлар”әсәре белән классик булып танылган Гадел Кутуй хикәяләре аерып бер урын алып торалар, аның геройлары аерым бер төгәллек белән тасвирланганнар. Сәнгатьне яратакан, сәнгать дөньясында кайнап яшәгән Г.Кутуй геройларын да шуннан сайлый.

Ә.Еники әсәрләре татар әдәбиятында, гомумән, үзе бер дөнья хасил итә, мәгънәсендә фәлсәфи – мәңгелек проблемалар куеп, шулар турында инде ничәнче буын укучыларны уйландырып – дулкынландырып тора.

Ә.Еники иҗатының үзенчәлекләре шунда, ул нинди вакыйга турында язса да, игътибарын кешенең шушы мизгелләре хәленә, халәтенә юнәлтә. Сугыш үзе вакыйгалар өермәсеннән тора да, Ә. Еники сугыш чоры әсәрләрендә хәрәкәт аз, әмма күңел кичерешләре, хисләр гамасы бик бай.

“Бер генә сәгатькә” хикәясе, исеменнән үк күренеп торганча, бер сәгатьлек вакытны иңли. Шул бер сәгать ут эчендә йөргән улларын көткән аналар өчен азмы, күпме? Моны беркем дә, хәтта хикәя геройлары да әйтә алмас. Шундый каршылыклы хисләрдән төзелгән әсәр бу: аерылу – күрешү – тагын аерылышу. Шулай да бу бирешү инде катая, бирешә башлаган Мәрьям

абыстайга тереклек суы кебек тәэсир итә, аның киләсе очрашуга өмете-ышанычы ныгый.

Бөек Ватан сугышы елларында татар халкының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыгы. Сугыш елларында әдәбиятның роле, аның алдына куелган бурычлар. Сүз сәнгатенең кешедә матурлыкка омтылыш тәрбиялисе урында чиксез нәфрәт уятырга хезмәт итә башлавы. Әдәби төрләрдән поэзиянең активлашуы.

**М.Җәлил (1906-1944).** Дөнья күләмендә танылган шагыйрь һәм сугыш каһарманы М.Җәлилнең (1906-1944) тормыш юлы. Әдәбияттагы беренче адымнары. Иҗатының романтизм белән сугарылуы. Әсәрләренең тематикасы, сәнгатьчә үзенчәлеге. Журналистлык һәм иҗтимагый эшчәнлеге. Татар опера театрын оештырудагы тырышлыгы. «Алтынчәч», «Илдар» либреттолары.

«Хат ташучы» поэмасы – сугышка кадәрге татар шигъриятенең уңышлы әсәре.

Егерменче-утызынчы еллар иҗатында сәнгатьчә табышлар, тел-сурәтләү чараларын кулланудагы, шигырь строфикасындагы эволюция. Бөек Ватан сугышы елларындагы иҗаты. «Тупчы анты» җыентыгы, андагы әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше.

М.Җәлил – хәрби курсант, сугышчы, шагыйрь. Әсирлек шартларындагы шигъри һәм гражданлык батырлыгы. «Моабит дәфтәрләре». Аларның Татарстанга кайту тарихы. Шигырьләрендә шагыйрьнең лирик образы. Әсәрләрдәге конфликт, аларның кискенлеге, кичереш тирәнлеге, халыкны, туган илне ярату хисләре, дошманга каршы нәфрәт гәүдәләнү. «Җырларым», «Ышанма», «Кичер илем», «Кошчык», «Ирек» әсәрләрендә автор образы, аның рухи көче гәүдәләнү. Лирик каһарманның нык ихтыярын, инанганлыгын күрсәтүдә «Егет көче», «Үлемгә», «Катыйльгә» һ.б. әсәрләре. «Ана бәйрәме», «Сандугач һәм чишмә» балладаларының идея-эстетик үзенчәлеге. Аллегорик образлар тудыруда традиция һәм яңачалык. Лирик герой уйларындагы фәлсәфи тирәнлек.

Фашизмның ерткыч асылын, кешелекнең иң явыз дошманы булуын аяусыз фаш иткән «Бүреләр», «Вәхшәт», «Сакчы» һ.б. шигырьләре. Безнең сугышчының кешелекле табигатен һәм фашистларның ерткычлыгын ачуда шагыйрь кулланган капма-каршы кую чаралары. Әсәрләрендә халыклар дуслыгы идеясе. Шагыйрьнең киләчәккә ышаныч белән каравын белдергән «Сугыштан соң», «Төзүче», «Яңа ел теләкләре», «Шатлыкны каршылап» шигырьләре. Көлкеле әсәрләре.

**Фатих Кәрим**нең тормыш юлы. Әдәбиятка килүе. Балалар дәбиятын үстерүгә керткән өлеше. Заман мәсьәләләренә багышланган «Җиденче мич», «Тавышлы таң» поэмалары. Аларда күтәрелгән мәсьәләләр.

Илне саклау, халыклар дуслыгы турында уйланулары, бу темага язылган «Яшен яктысы», «Аникин» поэмалары. Шагыйрьнең репрессия корбаны булуы.

Ф.Кәрим – фронтовик шагыйрь. Гади солдаттан офицер дәрәҗәсенә күтәрелүе. Сугыш чорындагы шигъри җыентыклары: «Мәхәббәт һәм нәфрәт», «Моң һәм көч». Сугыш чоры татар шигъриятен дөнья мәйданына чыгарудагы өлеше. Хатын-кызларны илен җаны-тәне белән сөйгән, аның өчен авыр сынаулар кичерергә әзер итеп сурәтләгән поэмалары: «Гөлсем», Партизан хатыны». Төрле милләтләрнең сугышчан дуслыгын данлаган әсәрләре: «Идел егете», «Без бергә», «Разведкада» һ.б.

Әсәрләрендә безнең солдатның халыкчан холык-гадәте, лирик геройның уйлары һәм кичерешләре тирән бирелгән әсәрләр: «Сөйләр сүзләр...», «Кыр казы», «Кайтыр эткәң», «Назлы аккош җырлый...», «Ак күгәрчен», «Моң һәм көч», «Кыңгыраулы яшел гармун».

Ф.Кәрим – прозаик. Повестьларында фронт чынбарлыгы, сугышчы образларының бирелеше. Ф. Кәрим – драматург. Авторның «Шакир Шигаев» драмасы.

Әсәрләрендә авторның шәхси күңел дөньясының ачылуы.

Шагыйрьнең хатлары, аларның Ф.Кәримне шәхес буларак күз алдына бастырудагы әһәмияте.

Ф.Кәрим турындагы әдәби әсәрләргә, фәнни һәм тәнкыйть хезмәтләренә күзәтү.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты.
2) Публицистиканың башка жанрларга йогынтысы.
3) М.Җәлил, Ф.Кәрим иҗатлары.

**Гамәли биремнәр:**

1. И.Газинең “Алар өчәү иде” әсәрендә солдатның эчке рухи дөньясы бирелеш үзенчәлекләрен күрсәтергә.
2. Ә. Еники әсәрләрендәге психологизм үзенчәлекләрен ачыкларга.

**Глоссарий: к**онтраст – кеше характерының, предметның, күренешнең үзенчәлекләрен, сыйфатларын икенчесенә капма-каршы кую.

**Әдәбият:**


1. Каеннар сары иде... Ватан сугышы чоры әдәбияты – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2004.
2. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда, Т.5 – Казан: Татар кит.нәшр., 1989.
3. Мәҗитов З. Сугышчан поэзия – Казан: Татар.кит.нәшр., 1975.
4. http://www.tatknigafund.ru


## ТЕМА № 6
## ШӘЙХИ МАННУР (1905-1980),
## ХӘСӘН ТУФАН (1900-1981): ГҮЗӘЛ ГАМЬЛЕ ИҖАТ

**Аннотация:** Сугыштан соңгы унъеллыкта чынбарлыкны киң колач белән тасвирлаган әсәрләр. Сугыш һәм кеше темасы белән беррәттән хезмәт

ТЕМАсының да эшкәртелә башлавы. Мондый әсәрләренең төп герое. Сталин үлеме белән бәйле рәвештә әдәбияттагы иҗтимагый атмосфераның үзгәрүе.

**Мөһим сүзләр:** Сәяси максатчанлык, чор һәм шәхес, хезмәт темасы, авыл көнкүреше.

**Шәйхи Маннур (19051980).** Иҗат эшчәнлеге дауллы-шаулы 20 нче елларда башалана. Бер яктан аның иҗатына чор атмосферасы тәэсир итсә, икенче яктан Себердә, шахтерлар арасында яшәве һәм эшләве йогынты ясый.

Революция һәм гражданнар сугышы куйган таләпрләр Ш.Маннур иҗат итә башлаганда әле юкка чыкмаганнар. Шуңа күрә шагыйрь иҗатында гысъянчылык романтизмы үзен ачык сиздерә. Әмма “шигърият көчештән, дәвамлылыктан башка яши, үсә алмый”. XX гасыр башы даһилары Тукай, Дәрдмәнд, С.Рәмиевләр яшь шагыйрь иҗатына тәэсир итми калмый. Талантлы шагыйрь аларның сәнгати камиллеген яхшы аңлый, күңел, йөрәк аша үткәреп үзләштерә, тиз арада “үзенчәлекле шагыйрь буларак өлгереп җитә, яшьләрнең эчке хисләрен сәнгатьчә нәфис сурәтләр аша ачуга омтыла. 1928 елда гына да ул “Атым белән сөйләшү”, “Соңгы уйлар”,“Сагыну җыры”, “Бозлар актарылганда” кебек хәзердә шигъри яңгырашларын югалтмаган әсәрләрен иҗат итә. Революция каһарманы булган кызыл укчы яки күн тужуркалы комиссарны сурәтдәүдән, халык һәм чорның аерым шәхесе, аның кабатланмас сыйфатлары белән тасвирлауга күчә баруда, кеше күңеленең тирәнлеген, психологизмны чагылдыруда Ш.Маннурның татар поэзиясенә керткән өлеше бик зур.

30 нчы елларда Ш.Маннур кешелекле моңны, сагышны, үткәнне, мәхәббәт шатлыгын эпик алымнар аша сынландыру юлларын эзли, поэма жанрын үзенчәлекле шигъри табышлар белән баета. Есенин, Такташ (Такташның “Жир уллары” трагедиясе зур тәэсир итә) алымнарын турыдан-туры кабатлаудагы, артык тар, шәхси хисләрен җырлаудан арына барып ул тормыш байлыгын киңрәк аңлау, эчке яшәешнең мәгънәсен ачу юлына чыга.

“Колчеданлы таулар өстендә” (1929), “Чуен ташкыннар” (1930), “Меңнән бер кичә” (1935) поэмалары шул юлда үзенчәлекле казаныш булды.

Шагыйрь табигать хозурлыгында, аның әйтеп бетергесез, биниһая матурлыгында шәхес кичерешләренә кулай буяулар таба. Аның “Котып батырларына” (1938) шигыре табигатьне җиңгән кешене олылавы белән гыйбрәтле.

Мәңгелек сер белән тыныч яткан

Боз сахрасы, инде күрсенмә!

Озакламый тагын килербез без,

Җырыбыз янгырар күкрәк өстендә.

1941-1945 елларда Ш.Маннур сугышның бөтен фаҗигасы, дәһшәтен үз күзләре белән күрә. Гадәти, беренче карашка кечкенә генә булган вакыйгалар аша солдатның рухи дөньясын ачуга, бер-берсенә капма-каршы төшенчәләр булган мәхәббәт һәм сугыш турында уйлануларга зур урын бирә (“Чәчәкләр һәм снарядлар” балладасының исеме үк шуңа мисал булып тора). Шул юнәлештәге эзләнүләрен ул сугыштан соң да дәвам итә.

Шагыйрь игътибарыннан сугыштан соңгы хезмәт энтузиазмы да читтә калмый. 1953-1956 елларда бер-бер артлы “Олы хәзинә җирләрендә” (цикл), “Җир-әнкәнең сылу кызы” (шигъри повесть) әсәрләре барлыкка килә. 60 нчы еллар әдәбияты хакында сүз алып барганда Ш. Маннурның “Муса” романын әйтми калу мөмкин түгел. Бу роман – вакыйга, татар әдәбиятының улларын, халыкнын үз бабаларын барлый башлавын күрсәтүче вакыйга.

1959 елда Ш. Маннур М. Җәлил турында роман язарга керешә. Фактик материал туплау өчен, ул М. Җәлил эзләреннән Оренбург, Минзәлә якларында, шагыйрьнең туган якларында булып кайта, Волхов фронтында Муса сугышкан җирләрдә йөри, туристлар путевкасы белән Германиягә барып, Җәлилне төрмәдә күреп белгән кешеләр белән очрашып сөйләшә. Шушы җитди өйрәнү-тикшеренүләрне һәм иҗат газапларының нәтиҗәсе буларак, 1964 елда “Муса” романы язылып бетә. Композицион төзелешендә, характерлар бирелешендә аерым бәхәсле урыннар булуга карамастан, роман әдәби җәмәгатьчелек һәм

укучылар тарафыннан яратып, авторның зур уңышы итеп кабул ителә. Башта сатлык дип бәяләнгән, аннан герой итеп күтәрелгән, күпләгән истәлекләр, фәнни тикшеренүләр һәм эзләнүләр объекты булган Җәлил образын матур әдәбиятта сурәтләргә алыну өчен зур иҗади кыюлык кирәк була язучыга. Образны тудырудагы кыенлыклар бу очракта зур бер нәрсәгә бәйле: Муса Җәлил тормышта яшәгән, күпләр күңелендә сүнмәс эз калдырган реаль шәхес, ул – язучы фантазиясе белән генә барлыкка килгән образ түгел. Муса Җәлил тормышы һәм язмышының теге яки бу яклары укучыларга болай да таныш. Димәк, язучы Муса образын тарихи дөреслеккә туры килә торган рәвештә, шул ук вакытта укучы күзаллавын тагын да баета алырлык итеп бирергә тиеш.

**Хәсән Туфан (1900-1981)**. Татар совет поэзиясенең классик шагыйре Хәсән Фәхри улы Туфан 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән - 9 декабрьдә) элекке Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волосте (хәзерге Татарстан АССРның, Аксубай районы) Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Булачак шагыйрьнең әтисе Фәхри абзый иген игүдән тыш, сәгать төзәтү, пыяла кую, тимерчелек кебек эшләр белән шөгыльләнгән һәм бу һөнәрләргә балаларын да өйрәткән. Моның өстенә, аның өлкән уллары, һәр елны Себер һәм Урал якларына китеп, шахтада да эшләп кайта торган булганнар.

Хәсән укырга-язарга әтисеннән һәм үзлегеннән өйрәнә, ә 1905 елгы революциядән соң Кармәттә мәктәп ачылгач, шунда йөреп укый башлый. 1914 елның язында ул Тобол губернасының Ахман авылында яңа җир алып урнашкан абыйлары янына китә һәм җәен алар белән бергә бакыр колчеданы руднигында эшли. Шул елның көзендә абыйлары аны Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Үз чорының алдынгы уку йортларыннан саналган бу мәдрәсә Х. Туфанның белем даирәсен киңәйтүгә һәм әдәби иҗат эшенә тартылуына уңай йогынты ясый. Шунда ул Г. Ибраһимовтан әдәбият дәресләре тыңлый, шул ук мәдрәсәнең шәкерте Ш. Бабич оештырган түгәрәккә йөреп, шигырь серләренә өйрәнә, әдәби кичәләрдә С. Рәмиев, М. Гафури, С. Сүнчәләй кебек шагыйрьләрнең чыгышларын ишетә.

Җәйге каникул вакытларында яшүсмер егет, укуын дәвам итәргә акча юнәтү өчен, Урал рудникларында шахтер, сәгать төзәтүче, Лысьва металлургия заводында токарь булып эшли. 1917 елның Февраль көннәрен, аннары Октябрь революциясен ул шунда, Лысьва заводында, каршылый.

1918-1924 елларда Х. Туфан Урал һәм Себер мәктәпләрендә балалар укыта. 1924 елның җәендә Казанга килә һәм 1928 елга кадәр Н. Нариманов исемендәге 17 нче номерлы Бишбалта мәктәбендә укытучылык хезмәтен дәвам иттерә.

Х. Туфанның исеме матбугатта беренче тапкыр 1924 елда күренә. Шул елны «Октябрь баласы» журналы һәм «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә аның берничә шигыре басылып чыга. Шуннан соң үткән ике-өч ел эчендә исә ул татар шигъриятенә һәм эчтәлек, һәм форма җәһәтеннән яңа бер аһәң, сыйфат алып килгән үзенчәлекле шагыйрь булып таныла. Бу елларда Х. Туфан поэма жанрында аеруча зур иҗади уңышларга ирешә. Тематик яктан нигездә Урал эшчеләре тормышыннан алып язылган «Урал эскизлары» (1926), «Ике чор арасында» (1927), «Башлана башлады» (1927), «Бибиевләр» (1927) кебек лиро-эпик әсәрләрендә шагыйрь тормыш фактларын чынбарлык күренешләрен заман турындагы фәлсәфи уйланулары белән тыгыз бәйләп, революция чорындагы социаль атмосфераны, искелек белән яңалык көрәшен, идеяләр бәрелешен, шул процесста тормышның, кеше шәхесенең ничек үзгәрә, яңара баруын җанлы картиналар һәм колоритлы эшче характерлары аша ачып бирә. Чорның әһәмиятле темаларын, әхлакый фәлсәфи проблемаларын зур социаль яңгырашлы итеп гәүдәләндерүе, сөйләм теленә нигезләнгән язу стиленең яңача шигъри чараларга, образларга бай булуы белән бу поэмалар егерменче еллар татар совет поэзиясенең үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр.

1928 елның язында Х. Туфан Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүле сәяхәткә чыгып китә. Анын бу сәяхәте ике елга сузыла. Сәяхәттә йөргәндә ул төрле халыкларның тормышлары белән якыннан таныша, халык иҗаты әсәрләрен өйрәнә, ашуглар, акыннар белән очрашып сөйләшә. Болар һәммәсе шагыйрь иҗатын яңа темалар, яңа хисләр белән баеталар. Сәяхәттән сон Туфан

поэзиясендә лирик агым, халыкчан образлылыкка игътибар бермә-бер көчәя, ул халыкның лирик җыр традицияләренә йөз бора башлый.

Сәяхәттән кайткач, Х.Туфан 1930-1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар редакторы, аннары 1937 елга кадәр «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы| секретаре булып эшли. 1940-1956 елларда аңа кабат Себердә булырга, ул якларның тормышы белән ныклап танышырга һәм хәтер хәзинәсен яңа тәэсирләр, истәлекләр белән тулыландырырга туры килә. 1956 елның җәендә Хәсән Туфан Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши.

Утызынчы елларда шагыйрь иҗатында күзәтелгән лирик-философик юнәлеш («Ант» поэмасы, 1935) һәм сәнгатьчә гадилеккә омтылу тенденциясе («Озату», «Ак каен» җырлары, «Тимеркәй турында баллада», «Юкмыш бабай малае» әкият-поэмасы һ. б.) елдан ел тирәнәя һәм яңа поэтик сыйфатлар белән байый барып, кырыгынчы-илленче елларда дәртле-кайнар хис, тирән фикер поэзиясе булып өлгерә. Бу чорда иҗат ителгән «Алга барышлый», «Иртәләр җитте исә», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Үзеңә бүләк итәсе иде», «Чәчәк сибелә җилдә», «Моабитны күрдем төшемдә», «Агыла да болыт агыла», «Сиңа», «Ромашкалар», «Тамчылар ни диләр», «Тургай нигә дәшми», «Әйткән идең», «Иртәләрем-кичләрем», «Сөйли торган материя», «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?», «Сүз кушасы килә талларга», «Һиндстанны эзлим», «Төннәрдә дә уяу далада» кебек лирик-фәлсәфи шигырьләре хис-фикер, форма, композиция бөтенлеге-камиллеге ягыннан татар поэзиясенең лирика жанрындагы энҗеләр булып саналырга хаклы.

Алтмышынчы-җитмешенче елларда да шагыйрь үз иҗат принципларына туры калып, югары гражданлык идеяләре белән сугарылган күп санлы лирик, публицистик шигырьләрен, поэма һәм балладаларын («Тимә Ибәтемә», «Упкыннар өстендә», «Кайда син, романтика?», «Еракларга алып киттеләр», «Могикан» һ.б.), тематик шигырь циклларын («Ә үткәнгә хатлар бармыйлар», «Лирик хатлардан», «Кармәт истәлекләре» һ. б.) иҗат итә. Шагыйрьнең бу

еллар иҗатында шулай ук сатирик һәм юмористик шигырьләр дә зур урын били.

Гомумән, Х. Туфан, тормыш һәм иҗат юлында нинди генә хәлләргә очрамасын, бервакытта да туган иленә, халкына һәм поэзиягә булган тирән ышанычын югалтмады. Аның халык әдәбиятына нигезләнгән иҗаты, татар классик поэзиясенең традицияләрен алга таба үстереп һәм киңәйтеп, үзенә, бер шигъри дөнья булып формалашты. Ул татар шигырен яңа эчтәлек, яңа ритмик ачышлар, лирик композициянең, строфа төзүнең классикага әверелердәй яңа үрнәкләре белән баетты.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Хәсән Туфан ике тапкыр (1970, 1980) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, ә «Сайланма әсәрләр» (Казан, 1964) китабы өчен аңа 1966 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Хәсән Туфан 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды. Ул 1934 елдан СССР Язучылар союзы члены иде.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Ш.Маннурның "Җир-әнкәнең сылу кызы" (1953-1956) шигъри повестенда нинди мотивлар кулланыла. "Муса" (1964) романында герой шагыйрь образына анализ ясагыз.

2) Х.Туфанның 60 еллар иҗатында иҗтимагый-фәлсәфи лириканың көчәюе нидә чагыла? "Еллар, ахры, байтак үткәннәр", "Сәлам сиңа, тормыш", "Кармәт истәлекләре" һ.б. әсәрләре мисалында.

**Гамәли биремнәр:**

1. Ш.Маннурның беренче шигъри тәҗрибәләре. Хезмәт пафосын һәм социалистик ярышны гәүдәләндергән "Колчеданлы таулар итәгендә", "Чуен ташкыннар", "Бетончылар җыры" поэмалары.

2. Ватан сугышы чоры лирикасында яшәү, тормыш, сөю турында уйланулар.

3. “Муса” романында герой шагыйрь образын беренчеләрдән булып тасвирлавы.

4. Х.Туфанның катлаулы һәм фаҗигале тормыш юлы. Башлангыч чор иҗатындагы “Зәңгәр бүре”, “Еллар чигәсендә”, “Урал эскизлары”, “Ике чор арасында”, “Башлана башлады”, “Бибиевлар” поэмаларында искелек белән яңалык көрәшен бирү.

5. Шагыйрьнең тоткынлык лирикасының фәлсәфи эчтәлеге, Тематик киңлеге ( “Үзеңә бүләк итәсе иде”, “Агыла да болыт агыла” һ.б.). Сурәтле фикерләвендә үзгәрешләр, сугыш темасына тоткын шагыйрь карашы (“Гөлләр инде яфрак яралар”, “Моабитны күрдем төшемдә” һ.б.).

**Глоссарий:** лирика – авторның субъектив шәхси хисләрен чагылдыручы әдәби төр.

**Әдәбият**:

1. Гайнетдинов М. Давылларда, җилләрдә: Хәсән Туфанның тормыш һәм иҗат сәхифәләре – Казан : Татар. кит.нәшр., 1989.

2. Вәлиулла И. Мәңгелек бәхет эзеннән // Казан утлары – 2000, № 11.

3. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 639 б.

## ТЕМА № 7
## ИБРАҺИМ ГАЗИ (1907-1971),
## ФАТИХ ХӨСНИ (1908-1996) ИҖАТЫ

**Аннотация:** И.Гази – проза остасы, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе. Язучы иҗатында җәмгыять үсеше белән кешеләрнең үсеше үрелеп бирелә.

Ф.Хөсни – иҗаты үзенчәлекле мәктәп булып саналырлык сүз осталарының берсе. Аның әсәрләре укучыларда һәрвакыт кызыксыну уята.

**Мөһим сүзләр:** Авыл яшәеше, зур үзгәрешләр, әхлак проблемалары.

**Ибраһим Гази (1907-1971).** Совет чоры татар әдәбиятының күренекле вәкиле – проза остасы, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Гази (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев) 1907 елның 4 февралендә хәзерге Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы Иске (Олы) Карамалы авылында крәстиян гаиләсендә туа. Бик яшьли ятим калып, бала чактан ук төрле михнәтләр, мохтаҗлыклар күреп үсә. 1919-1924 елларда ул Тәтештәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда урта белем ала, шунда комсомол сафына басып, актив җәмәгать эшчәнлеген башлый. 1924 елда яшь егетне Казандагы өлкә партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. 1926 елда мәктәпне уңышлы тәмамлагач, И.Гази башта комсомолның Кукмара волость комитеты секретаре, аннары Мамадыш кантон комитеты секретаре, 1929-1931 елларда исә комсомолның Татарстан өлкә комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире булып эшли. Бер үк вакытта ул Казанда чыга торган «Авыл яшьләре» журналында һәм «Кызыл яшьләр» газетасында мөхәррирлек вазифаларын башкара. 1927 елда Коммунистлар партиясенә әгъза итеп алына. Шушы ук елларда И.Газиның актив иҗат эшчәнлеге дә башлана. Аның беренче әдәби әсәрләре – лирик парчалары («Көлмә, Идел!», «Соңгы чаң» һ.б.) матбугатта 1929 елда басылып чыга. Шуннан соң иҗат ителгән «Кич алтыда» (1929), «Байраговның көнлек дәфтәреннән» (1930), «Көмеш сулы Нурминкә» (1930), «Бригадир кыз» (1931) кебек хикәя һәм кечкенә повестьларында автор шул чор эшче яшьләренең производстводагы хезмәт энтузиазмын, аларның искелеккә, әхлакый тотнаксызлыкка каршы көрәш картиналарын сурәтләргә омтыла. Сәнгатьлелек җәһәтеннән кимчелекләре булуга карамастан, шул чорның әдәби тәнкыйте бу әсәрләрне яшь авторның яңа кеше образларын иҗат итү юлындагы уңышлы адымы итеп бәяли.

1931-1942 еллар арасында И.Гази әүвәл Татарстан Язучылар оешмасында, аннары Мәскәүдә марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен милли телләргә тәрҗемә итү буенча махсус курсларда укып кайтканнан соң (1938), озак еллар нәшриятта мөхәррир һәм тәрҗемәче булып эшли, кырыгынчы еллар башында

берникадәр вакыт (1941, июль – 1942, август) “Совет әдәбияты” журналының җаваплы редакторы вазифаларын да башкара. Бу елларда ул рус һәм дөнья әдәбиятының аерым үрнәкләрен татар укучысына җиткерү буенча да нәтиҗәле эшли. А.Чехов, М.Горький, М.Салтыков-Щедрин, Мопассап, Золя кебек классик язучылардан эшләнгән әдәби тәрҗемәләре белән И.Гази үзен оста, иҗади тәрҗемәче итеп таныта. 1943 елдан башлап җиңү көннәренә кадәр И.Гази хәрәкәттәге армия сафында, фронтта татар телендә чыга торган «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә, шундагы кырыс шартларда күпсанлы очеркларын, бер төркем кыска хикәяләрен («Малай белән эт», «Әхмәт бабай», «Авылдаш» һ.б.) һәм «Алар өчәү иде» (1944) исемле повестен яза. Бу әсәрләрдә совет кешеләренең фронттагы батырлыгы, туган ил азатлыгы өчен явыз дошманга каршы көрәш картиналары сурәтләнә. Әдипнең сугыштан соң 1946 елда язылган «Без әле очрашырбыз» исемле повестенда да совет солдатының сугыштагы тарихи батырлыгы, аның бөек гуманизм һәм югары мораль-этик сыйфатлары үзәк тема итеп алына.

Ибраһим Гази әдәби иҗатының иң югары ноктасы сугыштан соңгы чорга – узган гасырның илленче һәм алтмышынчы елларына туры килә. Сугыштан соңгы чорның кырыс шартларында кешеләрнең тыныч хезмәттәге фидакарьлеген яктырткан «Алмагачлар чәчәк ата» повесте (1950), «Тургай картаямы икән?» һәм башка кече күләмле әсәрләрдән соң әдип киң колачлы эпик жанр – роман жанрында актив эшли башлый. 1956 елда ул Татарстан нефтьчеләренең хезмәтен, нефть җирендә яңа профессия кешеләре катлавы тууын сурәтләгән «Гади кешеләр» дигән романын тәмамлый. Катлаулы сюжетка корылган бу роман җанлы тормыш күренешләре, истә калырдай кеше образлары һәм, иң мөһиме, тел-сурәтләү чараларының халыкчан нәфислеге белән җәлеп итә. Роман үз заманының әдәби тәнкыйтендә нефть темасын яктырткан беренче күләмле проза әсәре буларак билгеләп үтелә.

Ибраһим Газиның эпик жанрдагы иң зур әсәре – «Онытылмас еллар» трилогиясе. Бу әсәрне әдип гомере буе эшли. Аның башлангычы «Балконлы

йортта» исеме белән әле сугышка кадәр үк (1934) басылып чыга. 1940 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Авыл җыены», «Патшаны төшергәч», «Озын Миңнулла» исемнәре астында аның тагын аерым бүлекләре басыла. Сугыштан соң автор үз күңелендә күптәннән иҗади бөреләнеп килгән бу әсәргә яңадан әйләнеп кайта һәм 1949-1966 еллар дәвамында бер-бер артлы аның өч кисәген («Малай чак», «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт», «Канатланыр чак») бастырып чыгара. Трилогия аерым-аерым китаплар рәвешендә рус теленә тәрҗемәдә дә дөнья күрә. «Онытылмас еллар» – гомумсовет әдәбияты мәйданында тарихи-рево-люцион роман исеме белән аерым бер жанр буларак формалашкан эпик әсәрләрнең татар әдәбиятындагы матур бер үрнәге. Эчтәлеге белән ул татар халкы тормышындагы зур бер тарихи чорны иңли. Трилогиянең һәр кисәгендә Татарстан җирендә булган чын тарихи вакыйгалар һәм революцион көрәш эпизодлары тасвирлана. Беренче кисәктә инкыйлабкача татар авылы тормышы, крестияннәрнең көнкүреше, җирсезлектән һәм социаль гаделсезлекләрдән бөлгенлеккә төшүләре бәян ителгән булса, икенче кисәктә 1917 елгы Февраль һәм Октябрь вакыйгалары һәм Гражданнар сугышы күренешләре, азатлык һәм бәхетле киләчәк өчен көрәшкә күтәрелгән халык улларының гыйбрәтле язмышлары тасвирлана; өченче кисәк исә, нигездә, әсәрнең баш каһарманы Хәлимнең аңлы кеше булып җитлегүен, авылда хосусый хуҗалыкларны күмәкләштерү елларында аның яңа тормыш өчен башкарган эш-гамәлләрен, сөйгән кызы Кафия белән булган саф мәхәббәт хисләрен, канатлы күңел кичерешләрен сурәтләүгә багышланган.

«Онытылмас еллар» трилогиясе өчен Ибраһим Гази 1969 елда Татарстан Республикасының Г".Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Язучылык хезмәте һәм иҗтимагый тормышта актив эшчәнлеге өчен ул шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы һәм ике тапкыр «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнә.

Ибраһим Гази 1971 елның 21 февралендә Казанда вафат була. Кабере Казанның Арча кырындагы рус зиратында.

**Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов)** 1908 елның 3 февралендә Татарстанның хәзерге Саба районы Олы Мәтәскә авылында туа. Авылда башлангыч белем алганнан соң, 1924 елда Казанга килә, Мулланур Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбенә укырга керә. Шунда укыганда шигырьләр яза башлый, ул шигырьләре «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Яңалиф», «Атака» журналларында басылып чыга. 1927-1930 еллар арасында иҗаты активлаша - ул күп кенә очерклар һәм «Көрәш кызы», «Усаллар» дигән драма әсәрләре дә яза.

1929 елда Ф.Хөсни Казан дәүләт университетының экономика факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, армиягә алына – 1933-1935 елларда Казандагы Беренче укчы дивизиядә элемтәче, соңрак хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, газета редакцияләрендә эшли, журналист буларак авылларда күп йөри, завод-фабрикалардагы эшчеләр белән таныша, тормышны, кешеләрне өйрәнә.  «Йөзек кашы», «Җәй башы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Мәйдан», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» исемле роман, повестьлары, күпсанлы хикәяләре белән ул татар әдәбиятының классигы булып танылды.

Ф.Хөсни иҗатында драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть жанрлары да күренекле урын алып тора.

Әдипнең «Урманда» (1938) комедиясе, «Әбли авылы» (1949), «Еллар-юллар» (1956), «Бертуган Таһировлар» (1965) драмалары, үз вакытында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, уңай бәя алды.

Ф.Хөснигә 1972 елда «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повесте һәм хикәяләре өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Ул шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе, «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнә.

Ф.Хөсни 1936 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Сугыштан соңгы татар прозасында тематиканың киңәюе, зур күләмле, киң колачлы әсәрләр иҗат ителүе нәрсә белән аңлатыла?

2) И.Газинең беренче иҗат тәҗрибәләре: Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында үзгәрешләр, персонажларның эчке дөньяларын тасвирлауга игътибар арту нәрсәдә чагыла? (“Алар өчәү иде”, “Якташ” һ.б.).

3) “Онытылмас еллар” трилогиясендә татар иҗтимагый тормышының эпик колач белән сурәтләнүе нәрсә белән аңлатыла? Язучы күтәргән милли мәсьәләләр.

4) Ф.Хөсни – хикәяләр остасы. “Йөзек кашы” повестындагы төп герой Айдарның үзенчәлекле характеры нәрсәдә чагыла?

5) “Утызынчы ел” романы. Шәхси язмышларны социаль вакыйгалар белән бәйләп, яшерен хакыйкатьне бирергә омтылышы. “Җәяүле кеше сукмагы”нда кеше язмышын тормыш катлаулылыгында тасвирлавы. Әсәрләргә, әсәрдәге геройларга характеристика бирегез.

**Гамәли биремнәр:**

1. И.Газинең “Онытылмас еллар” трилогиясендә тормыш хакыйкате. Язучы күтәргән милли мәсьәләләр.

2. Ф.Хөснинең милли характерлар иҗат итү юлындагы эзләнүләре. Романнарында геройлар эволюциясе, шәхси язмышларның социаль вакыйгалар белән бәйләнеше.

**Глоссарий:** Трилогия – бер авторның гомүм фикер белән берләштерелгән өч әсәре

**Әдәбият**:

1. Сафуанов С. Ибраһим Г – Казан: Татар. кит.нәшр., 1968.– 168 б.

2. Нуруллин И. Онытылмас еллар шаһиты: Тормыш һәм сәнгать чынлыгы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 17-32 б.

3. Галимуллин Ф. Онытылмас еллар сабагы// Мәдәни җомга. – 2007 – 9 февраль.

## ТЕМА № 8
## ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ (1911-1979), МИРСӘЙ ӘМИР(1907-1980) ИҖАТЫ.

**Аннотация:** Г.Әпсәләмов бөтен гомерен халыкка багышлаган тынгысыз әдип. Аның романнары безнең әдәбиятка яңа образ, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне үзенә туплаган герой алып килде.

М.Әмир иҗаты чынбарлык белән тыгыз бәйләнгән. Шулай ук үзенчәлекле юмор да, язучы иҗатының бер сыйфаты булып тора.

**Мөһим сүзләр:** производство темасы, иҗтимагый-сәяси тормыш, тормыш-көнкүреш чынбарлыгы.

XX йөз совет чоры татар әдәбиятының иң популяр каләм осталарыннан берсе – язучы Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе (хәзерге Мордва Республикасының Рыбкин районы) Иске Аллагол авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Алты балалы ишле гаиләдә иң өлкәне булып, авыл мәктәбендә өч сыйныфны тәмамлауга ук ул, Мәскәүдә яшәүче туганнары янына китә, укуын Н.Нариманов исемендәге 27 нче номерлы татар урта мәктәбендә дәвам иттерә. Шунда укыганда әдәби иҗат эше белән кызыксына башлый, Муса Җәлил мөхәррирлек иткән «Октябрь баласы» журналы һәм татар китапханәсе каршында оештырылган әдәби түгәрәккә мавыгып йөри, беренче шигырьләрен яза, хикәяләр, пьесалар язуда көчен сынап карый. Иҗат тәҗрибәләреннән берсе — «Әнвәр тегермәне» исемле шигыре – «Октябрь баласы» журналында басылып та чыга. Югарырак сыйныфларда укыганда һәм заводта эшләгәндә ул

инде Казандагы көндәлек матбугатта да актив язышa башлый, 1937 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Маһинур» исемле хикәясе дөнья күрә.

Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Габдрахман фабрика-завод өйрәнчекләре (ФЗӨ) мәктәбенә укырга керә, соңрак җиде елга якын Мәскәү заводларында слесарь һәм токарь булып эшли. Бер үк вакытта заводтагы төп хезмәтеннән аерылмыйча индустриаль-конструкторлык техникумында укый, 1940 елда исә читтән торып М.Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

1938 елның җәендә Г.Әпсәләмов Казанга килеп төпләнә, әдәбият-сәнгать кешеләре белән аралаша, әдәби иҗат активлыгын тагын да көчәйтә төшә. 1940 елда Казанда аның «Киләчәк безнеке» исемле өч пәрдәле пьесасы һәм 1941 елда хикәяләре тупланган «Бәхет кояшы» дигән күләмле генә җыентыгы басылып чыга.

1941 елның августында Г.Әпсәләмов сугышка китә. Әүвәл Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, аннары 1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр шул ук фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән татарча газетаның җаваплы сәркәтибе, 1945 елның җәеннән 1946 елның апреленә кадәр (армия хезмәтеннән кайтканчы) Ерак Көнчыгыштагы «Сталин сугышчысы» исемле фронт газетасында хезмәт итә.

Сугыш Г.Әпсәләмовның әдәби иҗат эшчәнлегенә зур йогынты ясый, ул әдип иҗатындагы төп темаларның берсенә әверелә. Бу тема, сугыш чорында иҗат ителгән күпсанлы хикәяләреннән, очеркларыннан («Икенче гомер», «Абушахман», «Төньяк балкышы», «Хәйбулла солдат», «Зәңгәр иртә», «Бөркет токымы», «Үлемнән көчлерәк» h.б.) һәм «Ак төннәр» (1946) исемле повестеннан тыш, аның сугыштан соң язылган күләмле романнарының да төп эчтәлеген тәшкил итә. Соңгыларында язучы, совет солдатының сугыш кырында күрсәткән батырлыкларын хикәяләү белән бергә, бу батырлыкның социаль чыганакларын ачыклауга, әсәр геройларының шәхес буларак формалашу, чыныгу эволюциясен күрсәтүгә, аларның характерындагы күркәм милли һәм

интернациональ сыйфатларны тасвирлауга зур игътибар бирә. «Алтын йолдыз» (1948) романы — шул юнәлештәге әсәрләрнең беренчеседер. Роман тиз арада укучыларның мәхәббәтен казана, ул рус теленнән тыш (русча тәрҗемәдә ул «Орлята» дип атала) поляк, украин, латыш, үзбәк, уйгыр телләрендә басылып чыга. Әдипнең реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган тагын өч күләмле әсәре — дошман амбразурасын күкрәге белән каплап батырларча һәлак булган Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинга багышланган «Газинур» (1951), фашизмның Бухенвальд дәһшәтләрен тасвирлаган «Мәңгелек кеше» (1960), герой-шагыйрь Муса Җәлилнең әдәби образын гәүдәләндергән «Агыла болыт» (1977) романнары да тормыш һәм сугыш чынбарлыгын яктыртуда шул чор татар прозасы ирешкән җитди казанышлар булып саналалар. Аларда фашизмга каршы көрәшнең интернациональ характеры раслана, төрле милләт кешеләренең халыклар азатлыгы өчен сугыш кырындагы бердәмлеге, дуслыгы һәм батырлыгы үзенчәлекле образлар, вакыйгаларның эзлекле үстерелеше аша, оста төзелгән сюжет һәм сәнгатьчә әдәби чаралар ярдәмендә ачыла.

Язучының иҗат мирасында сугыштан соңгы тыныч тормыш, хезмәт, мәхәббәт темалары белән бәйләнештә әхлакый проблемаларны күтәргән әсәрләр дә байтак. Шулар арасында иң күренеклеләреннән берсе – «Сүнмәс утлар» (1958) романы. Бер эшче гаиләсенең буыннан-буынга сузылган тарихи эволюциясен калку итеп сурәтләгән бу әсәре өчен Г.Әпсәләмов 1959 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Галимнәр, медицина хезмәткәрләре, табиблар хезмәтен һәм тормышын җанлы образларда гәүдәләндергән, укучылар арасында хәзерге көнгә кадәр яратып укыла торган «Ак чәчәкләр» (1966) романы, мәктәп, укытучылар тормышын әхлак проблемалары яссылыгында сурәтләгән «Яшел яр» (1968) романы, студентлар арасындагы интернациональ дуслык элемтәләрен яктырткан «Миңа унтугыз яшь иде» (1968), һәвәскәр рәссамның иҗат эшендәге газаплы кичерешләрен, шатлык-сөенечләрен бәян иткән «Идел хикәяте» (1971) кебек повестьлар, шул заманның тормыш чынбарлыгын төрле яклап чагылыш тапкан дистәләрчә хикәяләр, очерклар, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре,

публицистик язмалар һәм истәлекләр –болар һәммәсе Г.Әпсәләмов иҗат эшчәнлегенең гаять тә киң кырлы һәм тематик яктан бай булуы турында сөйлиләр.

Г.Әпсәләмов әсәрләрендә хезмәт кешесенең ватандарлык, гражданлык сыйфатлары – туган илгә һәм халкына бирелгәнлеге, патриотик хисләре, сугыш кырындагы һәм хезмәттәге батырлыгы – калку рәвештә, авторның үз язу стиленә хас күтәренке рух, романтик пафос белән сурәтләнә. Аның бай әдәби мирасы совет чоры татар әдәбияты хәзинәсенә кыйммәтле бер өлеш булып керә.

Заманында Г.Әпсәләмов бөтенсоюз аренасында зур популярлык казанган татар язучыларының иң күренеклесе. 1940-1983 еллар арасында гына да татар, рус телләрендә, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә әдипнең йөзгә якын басмада китабы дөнья күрә. Аның аерым әсәрләре әле дә кат-кат басылуларын дәвам итә.

Г.Әпсәләмовның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Ул рус язучылары А.Гайдарның «Тимур и его команда» («Тимур һәм аның командасы», 1941), Э.Казакевичның «Весна на Одере» («Одерда яз», 1951), А.Фадеевның «Молодая гвардия» («Яшь гвардия», 1950; 1956) романнарын һәм В.Короленко, Н.Лесков, Д.Мамин-Сибиряк, М.Пришвин, А.Новиков-Прибой һ.б. проза әсәрләрен тәрҗемә итә.

Г.Әпсәләмов үз заманының иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашкан язучы да. Ул элекке СССРның алтынчы чакырылыш Югары Советы депутаты була, күп тапкырлар РСФСР һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәләренә әгъза итеп сайлана, озак еллар «Казан утлары» һәм «Дружба народов» журналларының редколлегияләре составында эшли. Фронттагы һәм татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Габдрахман Әпсәләмов озакка сузылган авырудан соң 1979 елның 7 февралендә Казанда вафат була.

**Мирсәй Әмир (1907–1980).** Совет чоры татар язучыларының олы буыны вәкиле – күренекле прозаик, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмир (Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров) 1907 елның 6 гыйнварында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Мәләвез районы) Җиргән авылында игенче гаиләсендә туа. Әти-әнисеннән яшьли ятим калып, башта туганнан туган абыйсы гаиләсендә, аннары балалар йортында, һәм Эстәрлетамак шәһәрендәге җидееллык үрнәк-тәҗрибә мәктәбе интернатында тәрбияләнә. 1925 елда мәктәпне тәмамлагач, Башкортстанның хәзерге Авыргазы районы Яңа Карамалы авылында волость башкарма комитеты хезмәткәре һәм бер үк вакытта авыл комсомол ячейкасы секретаре булып эшли, Башкортстандагы «Яшь юксыл» газетасының селькоры да була. 1926 елда Казанга килә һәм сәнгать техникумына укырга керә. Шул елда «Авыл яшьләре» журналының ноябрь санында аның «Дуслар һәм дошманнар» исемле беренче хикәясе, аннары, күп тә үтми, үз рәсемнәре белән бизәлеп, «Сәйфулла», «Әби васыяте» дигән хикәяләре басыла.

Техникумның ике курсын тәмамлаганнан соң, М.Әмир, әдәбият дөньясына якынрак тору өчен, «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» редакцияләренә җаваплы сәркәтип булып эшкә урнаша. Бу чорда яшь әдипнең көндәлек матбугатта авыл тормышына багышланган күп кенә хикәяләре («Үткәннәр», «Замана үзенекен итте», «Куркыныч урыннар», «Хафиз бармагы», «Җанлы бүкән», «Әбелгата күпере», «Бәхет порошогы» һ.б.) басыла, ә 1929 елда аерым китап булып «Пар күгәрчен» исемле хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Шушы беренче әсәрләрендә үк М.Әмир үзен тормыштагы үзгәреш-яңалыкларга сизгер һәм халыкчан юмор белән сугарылган үткен-җор телле каләм иясе итеп таныта.

1929-1931 елларда М.Әмир Кызыл Армия сафында хезмәт итә: башта полк мәктәбендә укый, соңрак Идел буе хәрби округының Казан горнизонында татарча чыга торган «Кызылармеец» газетасында журналист булып эшли, газетаның күчмә редакциясе белән Урта Азиягә барып, татар-башкорт солдатлары арасында ЛОКАФның (Кызыл Армия һәм Кызыл флот язучылары

берләшмәсе) татар әдәбияты түгәрәкләре оештыру эшен башкара. Армия хезмәте аның иҗатына яңа темалар алып килә. 1930-1933 еллар арасында әдип тыныч дәвердәге хәрби тормыш күренешләрен, ил сагына чакырылган авыл егетләренең сугыш һөнәренә өйрәнүләрен кызыклы, көлкеле ситуацияләргә куеп тасвирлаган «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» исемле повестен һәм «Аяк», «Сугыш сере», «Клим малайлары» кебек хикәяләрен иҗат итә. Хәрби темага «Командир» («Карамалы егете») исемле зур роман язарга да керешә, ләкин әсәр тәмамланмыйча кала (беренче кисәге 1934 елда аерым китап булып басылып чыга).

Армиядән соң, 1931-1932 елларда, М.Әмир ТатЛОКАФның идарә сәркәтибе булып эшли. 1932 елда ул Татарстан Язучылар берлеген оештыру комитетына сәркәтип итеп билгеләнә. 1933-1935 елларда «Чаян»журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип эшен башкара. 1934-1936 елларда марксизм-ленинизм институтының аспирантурага хәзерлек бүлегендә укый. 1936-1937 елларда Татарстан дәүләт нәшриятының (Татгосиздат) матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли.

1937 елда М.Әмир яшерен тавыш бирү нәтиҗәсендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлана. Ләкин тоталитар режимның шул елда махсус оештырган репрессияләр шаукымы М.Әмирне дә читләтеп үтми: әле ике ай элек кенә Татарстан Язучылар берлегенә рәис итеп сайланган әдипне милләтчелектә гаепләп, НКВД органнары кулга ала һәм Казандагы Пләтән төрмәсенә яба. Суд тикшерүе барышында М.Әмир үзен батырларча тота, ялган гаепләүләрне кире кага һәм 1939 елда, гаебе расланмыйча, суд тарафыннан акланып, иреккә чыгарыла. 1939 елда М.Әмир Мәскәүдәге Әдәбият институтының читтән торып уку бүлегенә укырга керә.

Башта ук әдәби иҗатын яңа чынбарлык белән тыгыз бәйләгән М.Әмир утызынчы елларда үзенең игътибарын авылда барган үзгәрешләрне яктыртуга юнәлтә. Колхозлашу хәрәкәтенең башлангыч чорында авылдагы сыйнфый көрәш күренешләрен публицистик пафос белән сурәтләгән һәм колхоз җитәкчесенең үзенчәлекле образын гәүдәләндергән «Безнең авыл кешесе»

(1933) исемле повестеннан соң, 1935 елда әдип шул ук темага «Агыйдел» дигән атаклы әсәрен яза. Күп планлы, күп геройлы, драматик вакыйгаларга бай, шул ук вакытта яшьлеккә хас якты, романтик хис, тирән җылылык белән сугарылган бу повесть тиз арада укучыларның тирән мәхәббәтен яулап ала һәм әдәби тәнкыйтьтә утызынчы еллар татар прозасының күренекле казанышларыннан берсе итеп бәяләнә. Соңыннан, җитмешенче елларда, М.Әмир «Агыйдел» повестен пьеса итеп тә эшли, һәм шул пьеса өчен язучы 1974 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Ватан сугышы елларында Мирсәй Әмир бөтен талант көчен җиңү көнен якынайтуга юнәлдерә. Сугышның беренче көннәрендә үк ул, кулына каләм алып, фашистларга нәфрәтле уй-хисләрен һәм җиңүгә ныклы ышанычын чагылдырган «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр!» исемле оптимистик хикәясен иҗат итә. Совет информбюро хәбәрләренә таянып, Украина партизаннарының илбасарларга каршы көрәше турында «Йөрәк уты» («Партизан Иван») дигән пьесасын, фашист оккупантларын фаш иткән «Киез итек вакыйгасы» (1942) дигән сатирик комедиясен, «Дуслар» (1942), «Җавап хаты» (1942) исемле хикәяләрен мәйданга чыгара.

1941-1943 елларда М.Әмир Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире (вакытлыча рәис тә, баш мөхәррир дә) булып эшли. 1943 ел башында Язучылар берлеге командировкасы белән (партиянең ӨК карары буенча) Төньяк-көнбатыш фронтка сәфәр кылып, өч айга якын «Ватан өчен» исемле хәрби газета редакциясендә эшләп кайта. Шул газета битләрендә һәм соңыннан республика матбугатында совет кешеләренең сугыш кырындагы һәм тылдагы батырлыкларын, югары рухи-әхлакый сыйфатларын, тормышка, туган җиргә мәхәббәт хисләрен публицистик-лирик планда тасвирлаган берничә дистә әдәби очерк һәм дистәләгән хикәяләрен бастыра («Агитатор», «Коттыбый батыр», «Дошман көтмәгәнчә», «Курай», «Гөрли Казан», «Сыерчык», «Беркатлы кеше», «Бабайлар», «Мөстәкыйм карт йокысы», «Якташ» һ.б.). Шул ук фронт газетасы битләрендә М.Әмир фашистларны үткен сатира утына алган «Чаян фронтта» дигән яңа рубрика да ачып җибәрә

(«Табышмак әйтәм, тап!», «Әйдә шулай булсын», «Тотса мәскәүләр якаң», «Немецчә бишек җыруы» һ.б.).

Утызынчы еллар ахырында ук «Җәдәч» (1939), «Көнлекче Әхмәт һәм аның матур хатыны» (1939), «Тун ачуы» (1940) кебек кече күләмле комедияләр язган М.Әмир сугыш чорында һәм сугыштан соңгы беренче елларда драматургия жанрына аеруча еш мөрәҗәгать итә. Бу өлкәдә аның иң зур иҗади уңышы итеп «Миңлекамал» драмасын (1944) исәпләргә кирәк. Бу әсәрендә ул ил азатлыгы хакына теләсә нинди авырлыкларны да җиңә ала торган нык ихтыярлы, рухи яктан бай һәм оптимист күңелле татар хатын-кызының реалистик образын тудыра. Сугыш чоры авылының хезмәт энтузиазмын, батырлыгын әхлак, мәхәббәт проблемалары белән бергә үреп сурәтләгән «Тормыш җыры» драмасы (1946), халык иҗатына нигезләнгән күңелле «Гөлшаян» комедиясе (1948), Казан галимнәренең сугыш елларындагы фидакарь хезмәтен һәм тормыш-көнкүрешен чагылдырган «Профессор Саматов» (1949) пьесасы, сугыштан соңгы чынбарлыкка багышланган «Җыр дәвам итә» (1947), «Наилә» (1947), «Минем хатын» (1955), совет хакимиятенең беренче елларында авылдагы катлаулы сыйнфый көрәш күренешләрен кырыс буяуларда тасвирлаган «Хөрриәт» (1960) исемле драма-комедияләре белән М.Әмир татар сәхнә әдәбияты үсешенә сизелерлек өлеш кертә.

Гәрчә драматургия М.Әмир иҗатында мөһим урын алып торса да, әдипнең илленче-җитмешенче еллар арасындагы иҗади уңышлары күбрәк проза жанры белән бәйле. 1953 елда ул «Ялантау кешеләре», ә 1959 елда аның дәвамы булган «Саф күңел» исемле романнарын тәмамлый. Соңыннан, «Саф күңел» исеме белән икесе бергә басылып чыккан бу дилогиядә, автор сугыш чоры чынбарлыгының киң панорамасын күз алдына китереп бастыра, совет кешеләренең ил алдындагы гражданлык бурычларын сугыш кырында да һәм тылда да бердәй фидакарьлек, намус сафлыгы белән үтәүләрен калку итеп гәүдәләндерә. «Саф күңел» дилогиясеннән соң язылган «Җан көеге» (1969) исемле повестенда исә язучы бөек сынау елларында шәхси мәнфәгатен ил-халык интересларыннан өстен куйган куркак җанлы, дезертир бер кешенең

гыйбрәтле язмышын бәян итеп, халык азатлыгы хакына үз-үзен аямыйча көрәшүнең кеше өчен иң изге максат булуын раслый.

Юмор – М.Әмир талантының тагын бер төп үзенчәлекләреннән берсе. Аның 1971 елда иҗат ителгән һәм укучылар арасында киң популярлык казанган «Балыкчы ялганнары» исемле повесте, маҗаралы һәм юмористик стильдә язылуыннан тыш, табигатькә мөнәсәбәттә кешенең рухи дөньясы һәм әхлакый йөзе, тормыштагы позициясе кебек мөһим мәсьәләләрне күтәрүе белән дә әһәмиятле. «Мыжык карт язмалары» дигән повесте да (1975) укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Гомеренең соңгы елларында әдип автобиографик материалларга нигезләнгән әсәрләре өстендә эшли. «Без бәләкәй чакларда», «Үсә төшкәч», «Казан» дигән өч кисәктән торган һәм язучының утызынчы елларга кадәрле тормышына бәйле вакыйгаларны эченә алган бу повестьлар әүвәл 1979, 1982 елларда аерым ике китап булып («Без бәләкәй чакларда», «Хатирәләр урманы»), ә 2002 елда өчесе бергә «Кичә турында бүген» дигән исем белән басыла.

М.Әмир – «Калку кырга кар ява» (1933), «Алдакчы бозау» (1940, 1959), «Батыр исемле малай турында хикәяләр» (1941; 1968 елда тулыландырылган 5 нче басмасы чыга), «Әниләре өйдә юкта» (1946), «Зур бүләк» (1956) кебек балалар өчен язылган китаплары, «Кысыр хәсрәт» (1954) кебек юмор-сатира җыентыклары, күпсанлы публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм тәрҗемә әсәрләре авторы. Аерым алганда, ул И.Тургеневның «Отцы и дети» («Аталар һәм балалар», 1949) романын, Б.Горбатовның «Непокоренные» («Буйсынмас кешеләр», 1944), Г.Гулианың «Весна в Сакене» («Сакен язы», 1950), В.Короленконың «Слепой музыкант» («Сукыр музыкант», 1954) повестьларын, В.Вишневскийның «Незабываемый 1919-й» («Онытылмас 1919 ел», 1952), Н.Погодинның «Человек с ружьем» («Мылтыклы кеше», 1952), А.Корнейчукның «Платон Кречет» (1953), К.Симоновның «Дни и ночи» («Көннәр һәм төннәр», З.Солтанов белән уртак тәрҗемә) драмаларын, С.Аксаковның «Аленький цветочек» («Ал чәчәк»,1948), М.Лермонтовның

«Ашик-Кериб» («Гашыйк-Гарип», 1941) экиятләрен татар теленә тәрҗемә итә. Аның үзенең дә күп кенә әсәрләре рус теленә һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителә.

М.Әмир иҗтимагый-сәяси тормышта актив катнашкан язучы. Ул КПССның XXIII съезды делегаты, партиянең өлкә комитеты әгъзасы, РСФСРның ике чакырылыш Югары Советы депутаты (1963-1971), РСФСР Югары Советы Рәисе урынбасары (1967-1971), РСФСР Югары Совет Президиумы Рәисе урынбасары (1963-1967), РСФСР, СССР Язучылар берлекләре идарәсе әгъзасы булып сайлана; 1947-1959 елларда Казан шәһәр район советы һәм шәһәр советы депутаты була, утызынчы еллардан башлап гомеренең ахырларына кадәр Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, рәис урынбасары һәм рәисе булып эшли, 1940-1950 еллар арасында Берлекнең проза, драматургия, тәрҗемә секцияләрен җитәкли, озак еллар «Чаян», «Казан утлары» журналлары редколлегияләрендә әгъза булып тора, 1937 елда ике ай һәм 1961-1968 елларда Республика Язучылар берлегенә җитәкчелек итә.

Иҗтимагый тормыш һәм әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен М.Әмир Ленин ордены, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр белән бүләкләнә, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була (1945).

Мирсәй Әмир 1980 елның 1 июнендә Казанда вафат була.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Г.Әпсәләмовның әдәби юнәлешен билгеләүдә Бөек Ватан сугышының роле. Чынбарлык биргән каһарманнарны әдәби образлар дәрәҗәсенә күтәргән күләмле романнары (“Газинур”, “Мәңгелек кеше”).

2) Бер гаиләнең тарихи эволюциясе аша эшчеләр тормышын сурәтләгән “Сүнмәс утлар” романына анализ ясагыз.

3) М.Әмирнең башлангыч чор иҗаты (1928-1930). “Безнең авыл кешесе”, “Агыйдел” әсәрләренең идея-тематик эчтәлеге, яшьләр образы аша бирелгән заман каршылыгы нидә чагыла?

4) М.Әмир драматургиясендә сугыш темасы.

**Гамәли биремнәр:**

1. “Ак төннәр”, “ Алтын йолдыз” әсәрләрендә сугыш вакыйгаларын яктырту үзенчәлекләре, язучы кулланган романтик алымнар.

2. Медицина хезмәткәрләрен, укытучылар тормышын әхлак, мәхәббәт проблемалары белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнгән “ Ак төннәр”, “ Яшел яр” романнары.

3. М.Әмирнең сугыш чоры авылының әхлак, мәхәббәт мәсьәләләрен күтәргән әсәре буларак “Миңлекамал” пьесасы. Әдип иҗатында юмор бизәкләре (“Мөстәкыйм карт йокысы”, “Балыкчы ялганнары” һ.б.).

**Глоссарий:** тема – әдәби әсәрнең нигезен тәшкил итүче проблемалар җыелмасы.

**Әдәбият:**

1. Мухамедова Г. Абдурахман Абсалямов: очерк жизни и творчество – Казань: Татар.кн. изд-во, 1971.

2. Нуруллин В. Сүнмәс утлар кабызган әдип // Мәдәни җомга – 2002 – 1 февраль.

3. Хатипов Ф. Мирсәй Әмир – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.

4. Нуруллин И. Киләчәк яктысында //Казан утлары – 1987, № 4.

5. Миңнуллин Ф. Талантлар юлы – Казан: Татар. кит.нәшр., 1994 – 207-208бб.

## ТЕМА № 9

## ГОМӘР БӘШИРОВ (1901-1999), ӘМИРХАН ЕНИКИ (1909-2000).

**Аннотация:** Г.Бәширов иҗатында илебез кичергән катлаулы чорлар – граңданнарйәҗ Бөек Ватан сугышы чагылыш таба. Аның әсәрләрендә, шулай ук, татар халкының милли яшәеш үзенчәлекләре дә бар төсмерләрендә балкый.

Ә.Еники иҗаты сугыштан соңгы дәвер татар әдәбиятында үзенә бер урын алып тора.

**Мөһим сүзләр:** Милли яшәеш, кешенең җәмгыятьтәге урыны.

**Гомәр Бәширов (1901-1999).** Арча төбәгенең Яңасала авылында туган. Татар халкының күңелен тетрәндергән моңлы һәм тирән тойгылар уята торган "Җидегән чишмә" җыры шигырен язган Гомәр Бәшировның (җырның көен халкыбызның сөекле композиторы Сара Садыйкова иҗат итте) бөтен әсәрләрендә дә илаһилык көче һәм моңы бар. Безнең сугыш һәм сугыштан соң килгән буын язучының "Намус" романын, "Сиваш" һәм "Туган ягым - яшел бишек" повестьларын, "Сарут" новелласын һәм гаҗәеп матур сюжетка корылган хикәяләрен укып үсте.

Арча ягындагы Яңасала авылында туган татар егете Гомәр Бәшир улы катлаулы һәм авыр тормыш юлы үтә. Мәктәп еллары да ул коточкыч болганчык елларда тиешле сурәттә үтми. Гаиләдә тормыш авыр булу сәбәпле, унөч яшьлек Гомәрне күрше авылның тегүче абзыена өйрәнчек итеп бирәләр. Ә өйрәнчекнең хәлен А.Горький хикәя-повестьларны укыган кеше бик яхшы күзаллый. Остаз-хуҗа ни теләсә, шуны эшли: ат кебек эшләтә, ит итеп дөмбәсли. Әмма шуңа карамастан Гомәр укый. Аның остазы да, әйдәп йөрүчесе дә китап була.

Ул елларны искә алганда өлкән язучының күзләреннән яше чыкмый калмый иде. Әмма нинди генә авырлыклар, хәтта үлем белән якалашкан чаклары булса да, Гомәр ага Кызыл Армия сафларында хезмәт иткән чакларын, хәрби акцияләрдә катнашуын, халык хакимиятен урнаштыру өчен сугышкан чакларын рәхәтләнеп искә ала, сөйли иде. Бигрәк тә Сивашны кичү, Ор капкасын, Кырымны зур җирдән аерып, саклап торган ур һәм үр аша бәреп керү һәм Врангель ак гвардиячеләрен тар-мар итүләр аның яшьлек хатирәсе иде. "Сиваш" дигән гаҗәеп матур итеп ана телебезнең сүз байлыгына, салмак кына тыныч агышыда тарихи мәгълүматларга таянып язган әсәре шул турыда.

Сугыштан чыныгып кайткан татар егете Гомәр Бәширов Арча кантоны милиция бүлегендә эшли. Аның гадел һәм тыныч холкын аңлаган хөкүмәт

кешеләре Балтач белән Дөбъяз төбәкләрендә халык тикшерүчесе, халык судьясы итеп билгели. Шул вакытта күргән, кичергән, үзе аша үткәргән вакыйгаларны тасвирлап ул республиканың "Кызыл Татарстан" газетасына юллап тора. Аннары үзе дә шул газетага эшкә күчә.

Гомәр Бәширов тирән белемле һәм зур тәҗрибәле остаз да, ә иң мөһиме, ул сабыр холыклы, кешелекле һәм саф вөҗданлы кеше иде. СССР Дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

**Әмирхан Еники (1909-2000) .** Күренекле әдип-прозаик Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев) 1909 елның 17 февралендә (яңа стиль белән 2 мартта) элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан АССРның Благовар районы) Яңа Каргалы авылында таза хәлле крәстиян гаиләсендә туа. 1911 елда аның әтисе гаиләсе белән Яңа Каргалыдан кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән дигән авылга күченә. Әмирханның балалык һәм мәктәп еллары шул авылда уза. Яшьтән үк әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган Ә.Еники 1925 елның җәендә Казанга килә һәм китап кибетенә курьер булып эшкә урнаша. Бер елдан ул Казан дәүләт университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда көндәлек матбугат битләрендә аның әдәби парчалары һәм хикәяләре күренә башлый.

1927-1933 еллар арасында Ә.Еники Донбасста – ликбез курсларында укытучы, Казан мех фабрикасында – сортировщик, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә штаттан тыш хәбәрче хезмәтендә була, бер үк вакытта төп эшеннән аерылмыйча, 1931-1933 елларда Казанда Хезмәтне фәнни оештыру институтында (ИНОТ) укый. Шуннан соң ул Ватан сугышына кадәр Казандагы җирле промышленность система сында техник укыту буенча методист (1934-1935), кинофикация трестында инструктор (1935-1936), «Азеркино» (Баку) студиясенең районлагы махсус вәкиле (1936-1937), Казанның 2 нче номерлы тегү фабрикасы каршындагы стахановчылар мәктәбендә (1937-1939) һәм Үзбәкстанның Маргилан шәһәрендәге гомумбелем бирү мәктәпләренең берсендә укытучы булып эшли. 1941-1945 елларда әдип —

Ватан сугышы фронтында: хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьларында рядовой солдат булып хезмәт итә.

Армиядән кайткач, Ә.Еники берникадәр вакыт «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр, аннары Татарстан Радиокомитетында әдәби тапшырулар бүлеге мөхәррире булып эшли, 1950-1952 елларда исә Казан авиация техникумында татар теле укыта. 1953 елда ул бөтенләе белән профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

Аерым журналистик язмалары һәм «Дус кеше» (1929), «Пожар» (1929), “Никуличева һәм аның иптәшләре» (1934), «Көзнең бер кичендә» (1939) Шикелле повесть, хикәяләре белән сугышка кадәр үк матбугатта исеме күренгәләсә дә, Ә.Еники үзенчәлекле язучы-художник буларак, нигездә, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда формалаша. Аның «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Ялгыз каз» (1944), «Мәк чәчәге» (1944), «Кунакчыл дошман» (1945), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады» (1956) кебек хикәяләре татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклы. Аларда дәһшәтле сугыш шартларында гади совет кешесенең рухи чыдамлыгы, тыйнаклыгы, юлындагы авырлык-кыенлыкларны батырлык белән кичерүе һәм тормышка, яшәүгә булган тирән ышанычы сәнгатьчә калку итеп сурәтләнә. Әдип барыннан да элек сугыш чынбарлыгының кеше рухында, табигате-холкында чагылышын анализлый һәм көндәлек тормыш вакыйгалары, детальләре аша үз геройларының эчке дөньясын, характер үзенчәлекләрен психологик төгәллек белән, тәэсирле итеп ачуга ирешә.

Тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылу илленче-җитмешенче еллар арасында әдипкә тагы да зуррак иҗади уңышлар алып килә. Язучының «Рәхмәт, иптәшләр!» (1951-1952), «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968), «Без дә солдатлар идек» (1971), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) исемле повестьлары, «Ялгызлык» (1957), «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Төнге тамчылар» (1964), «Коръән хафиз» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965), «Курай» (1970), «Тынычлану» (1978) кебек хикәяләре, кешеләр

арасындагы төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктыртуы һәм заманны борчыган әхлакый-этик проблемаларны кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә аерым игътибарга лаеклар. Геройның күңел серләренә тирән үтеп керә белү осталыгы, фикернең фәлсәфи үткенлеге һәм драматик киеренкелеге, форманың пөхтә һәм җентекле эшләнүе, тел-сурәтләү чараларының төрле стилистик буяуларга, образлы фикерләүдәге милли үзенчәлекләргә бай булуы – болар Ә.Еники талантының төп сыйфатларын тәшкил итәләр.

Ә.Еники иҗатында юмор-сатира, әдәби тәнкыйть, очерк, публицистика, мемуар жанры әсәрләре һәм әдәби тәрҗемәләр дә зур урын били. «Күсия ханым», «Күңелсез мәҗлес», «Кунакта», «Бөке», «Сыбызгы» кебек кыска хикәяләрендә («Чәнечкеле хикәяләр» җыентыгы) ул үткен-җор тел, оста тотып алынган тормыш детальләре ярдәмендә җәмгыятебездә очрый торган кире типларның гомумиләштерелгән сатирик портретларын күз алдына китереп бастыра. Гомумән, юмор-сатира Ә.Еники язу стиленең мөһим хасиятләреннән берсе булып, аның элементлары теге яки бу күләмдә язучының һәрбер әсәрендә диярлек очрый.

Ә.Еникинең иҗтимагый тормыштагы актуаль мәсьәләләргә багышланган публицистик мәкаләләре, очерклары, әдәбият-сәнгать турындагы уйланулары һәм истәлек язмалары, бергә тупланып, 1983 елда аерым китап булып чыга. Сиксәненче еллар башында исә «Казан утлары» журналы битләрендә (1981,№ 10,11; 1982,№ 12; 1985,№ 1,2) әдипнең яңа әсәре-автобиографик материалларга нигезләнеп язылган «Соңгы китап» исемле документаль повесте дөнья күрә.

Ә.Еники - әдәби тәрҗемә остасы. Ул украин язучысы О.Гончарның «Знаменосцы» («Байрак йөртүчеләр», 1951) романын, А.Островскийның «Без вины виноватые» («Гаепсез гаеплеләр», 1953) драмасын, М.Бубенновның «Белая береза» («Аккаен», 2 нче кисәк, 1954) романын, К.Паустовскийның «Летние дни» («Җәй көннәре», 1960) исемле хикәяләр җыентыгын, Э.Казакевичның «Синяя тетрадь» («Зәңгәр дәфтәр», 1964), Ч. Айтматовның «Беренче мөгаллим» (1965) повестьларын һәм күп кенә СССР халык әкиятләрен

татар теленә тәрҗемә итә. Аның үзенең дә төп әсәрләре рус теленә һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителгән.

Ә.Еникинең әдәби иҗаты Совет хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнә, ул Хезмәт Кызыл Байрагы (1979) һәм «Почет Билгесе» (1957) орденнары белән бүләкләнә. 1984 елда аңа «Юлчы» исеме белән чыккан хикәяләр җыентыгы һәм русча тәрҗемәдә басылган «Повести и рассказы» (1982) китабы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Ә.Еники – 1946 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде.

1985 елның 14 гыйнвар Указы нигезендә ТАССР Югары Советы Президиумының, мактау грамотасы белән бүләкләнә. Әдипкә 1989 елда «Татарстанның халык язучысы» дигән исем бирелә. 2000 елның 16 февралендә Казанда вафат була, Яңа бистә зиратына җирләнә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:**

1) Ә.Еникинең беренче иҗат тәҗрибәләре. Сугыш шартларында кешенең рухи чыдамлыгын сурәтләгән “Бала”, “Ана белән кыз”, “Бер генә сәгатькә”, “Кунакчыл дошман” хикәяләренә анализ ясагыз.

2) 50-70 еллар иҗатында тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылу, кешеләр арасындагы төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктыртуын ничек аңлата аласыз?.

3) Г.Бәшировның журналист һәм язучы буларак формалашуына ясага йогынты.

4) Сугыш елларындагы тыл батырлыгын сурәтләгән “Намус” романы. “Туган ягым – яшел бишек” романында халык тормышының, гореф-гадәтләренең сәнгатьчә үтемле тел-стиль чаралары ярдәмендә бирелеше. “Җидегән чишмә” романы.

**Гамәли биремнәр:**

1. Ә.Еникинең тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылуы. “Саз чәчәге”, “Рәшә”,

“Әйтелмәгән васыять” повестьларында заманны борчыган проблемаларга мөрәҗәгате.

2. Г.Бәшировның “Намус” романында татар хатын-кызларының күркәм сыйфатларын үзенә туплаган Нәфисә образы.

**Глоссарий: р**оман – катлаулы сюжетка корылган зур күләмле әдәби әсәр.

**Әдәбият**:


1. Миңнуллин Ф. Якты юллар: әдәби тәнкыйть мәкаләләре – Казан: Татар.кит.нәшр., 1975.
2. Сверигин Р. Фатих Хөсни һәм Әмирхан Еники прозасында сурәтләү чаралары: татар әдәбияты мәсьәләләре – 8 җыентык – Казан: Татар. кит.нәшр., 1978.
3. Идрисов Р. , Идрисова В. Югары һәм урта һөнәри уку йортларында татар әдәбиятын укытуның мөһим мәсьәләләре – Казан: КДУ, 2006.
4. Җәләлиева М. Татар совет әдәбияты тарихы: очерклар – Казан: Татар.кит.нәшр.,1960.
5. Әмир М. Үзебез турында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар – Казан: Татар. кит.нәшр., 1971.

# 1917-1960 ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ БУЕНЧА ТЕСТЛАР

## Татар әдәбияты тарихы (1917 – 1930 нчы еллар)

1 вариант

1. М.Гафуриның гомер юлын билгеләгез

а) 1880 – 1934; в) 1880 – 1926;

б) 1879 – 1933; г) 1886 – 1926.

2. Һ.Такташның 20 нче еллар ахырында яза башлап, тәмамланмаган әсәре

а) “Сыркыды авылы”; в) “Камил”;

б) “Таң җиле”; г) “Күмелгән кораллар”.

3. Г.Ибраһимовның беренче һәм бердәнбер драма әсәре

а) “Яшьләр”; в) “Яңа кешеләр”.

б) “Тигезсезләр”;

4. Г.Ибраһимовның “Безнең көннәр” романының үзгәртелмичә нәшер ителгән елы

а) 1920; в) 1918;

б) 1934; г) 1915.

5. Г.Ибраһимов оештырган, мөхәррирлек иткән журналлар

а) “Безнең юл” в) “Ялт-Йолт”

б) “Мәгариф”; г) “Яшен”.

6. М.Галәү чыгаруда катнашкан журнал

а) “Карчыга”; в) “Туп”;

б) “Ялт-Йолт”; г) “Әлгасрелҗәдит”.

7. К.Тинчурин үзен беренче чиратта ... жанрында оста язучы итеп танытты

а) драма; в) комедия.

б) трагедия;

8. М.Гафуриның эшчеләр язмышын “алтыны юылып, читтә ташланган ком” белән чагыштырган әсәре

а) “Ярлылар, яки өйдәш хатын” (1907); б) “Шагыйрьнең алтын приискасында” (1930);

в) “Кара йөзләр” (1927);

г) “Тормыш баскычлары” (1928).

9. М.Гафуриның “Кара йөзләр” повесты башланып киткән сюжет элементы

а) экспозиция;

б) төенләнеш;

в) вакыйгалар үстерелеше;
